# ОЧРАШУ ЯКИ ГӨЛГЫЙЗАР

## I

— Әйе, яшь вакытларда төрле эшләр очрый. Мин үзем элгәре андый бәхетләргә, очрашуларга хыяләт дип кенә карый идем,—дип, Габдулла әфәнде безнең сүзгә катышты. Без, биш-алты иптәш берлән төрлемез-төрле якка таралырга вакыт йетә башлаганга, Казанның бер бакчасына чәй эчәргә җыелган идек. Әлеге Габдулла әфәнде, безне бераз карап йөргәннән соң, безгә килеп кушылып чәй эчә башлады һәм безнең сөйләшә торган сүзгә дә катышты. Сөйләгән сүземез өйләнү, кыз алу, хатын табу, мәхәббәт кеби эшләр иде. Төрлемез төрлечә сөйләгәннән соң, Габдулла әфәнде дә үзенең башыннан үткән вакыйганы шул рәвешчә сөйләргә тотынды:

— Мин яшь вакытта үземчә, бераз мөселманча укыганнан соң, бәгъзе кешеләрнең әйтүләрене тыңлап, русча укырга тотындым. Минем яшемдәге (ул арада яшем унтугызда иде) кешеләргә кереп укырлык һич мәктәп юк иде. Баратора Казан дарелмөгаллиминенә керәчәк булдым һәм анда кердем. Анда укыдым. Фикерләр башкарды. Элгәре, мәдрәсәдә вакытта, халыкны икегә генә бүлеп, иң гали бүлеге — шәкерт, аннан калганнары һәммәсе — мужик, дип йөргәннәрем дөрес түгеллеге беленә башлады. Мәдрәсәдә вакытта: «Инсанның хакыйкате хайване — натыйк, ишәкнең — хайване сахил, фәләннеке — фәлән»,—дип укуларым берлән бөтен дөньядагы нәрсәне беләм, дип, һаваланып йөрүем дә бер эшкә дә ярарлык түгеллегене белдем. Мәдрәсәдә вакытта, мәчеткә кереп, фуражкасын артка киеп, намазыны укыган полицейскийны күргәндә, никадәр хамияте исламиям артып шатланган булсам да, шкулда укыгач, аның алай укуыннан да исламияткә артык файда юклыгыны белдем. Шкулда рус мөхәррирләренең төрле китапларыны укыдым. Тургенев, Толетой, Достоевский, Гончаров кеби зур мөхәррирләрнең әсәрләрен дә, әлбәттә, укымый калмадым. Бу китаплар бик файдалы булсалар да, башымны да бик аз чуалтмадылар. Мин төрле фикерләр берлән йөдәп чыга

идем. Халыкка файда итәргә, фәлән итәргә дип сөйләп, кайсы бәйрәм кичләрендә бөтен төнне йокламаенча үткәрә идек. Бер вакытта, авылда мужик булып, сука сукалап тору тиеш кеби күренә иде. Икенче бер вакытта, мөгаллим булып, халыкны укыту кирәк кеби беленә иде. Бәгъзе вакытта, акча ясап, йә ясалганына хуҗа булып, төрле яктан ярдәм итү фикеренә килә идек. Фараз берлән әллә ниләр эшли идек. Билфигыль, күзгә күренгән эш юк иде.

Белмим, хисси романнар бик күп укыганга, белмим, җитдирәк китаплар укыганга, белмим, башымнан төрле эшләр кичеп, балалыктан кешелеккә күчкәнгә, мәхәббәт, гыйшык кеби нәрсәләргә бик аз ышана идем. Шәрыктагы бер күрү берлән гашыйк булган кешеләргә, Аурупадагы бер кызның бер сүзе, йә бер хәрәкәте өчен булган дуэльләргә җөннүн генә дип карый идем. Бу карауларымны — хак, фәлән, дип кешегә кабул иттерергә теләү кая, бәлки һәрвакытта үземнең шундый хисләрдән гафил булуыма кайгыра идем, һәм дә дөнья тормышының рәхәте фамилия сәгадәтендә генә булганга, ул да мәхәббәт берлән генә табылганга, күңелемнән һәрвакыт үземнең зәгыйфемне белеп мәхзүн була идем. Мин бер кызны сөюне, теләсә матур булсын, теләсә булмасын, теләсә әхлаклы булсын, теләсә булмасын — бик зур бәхеттән саный идем. Ләкин үземнең һичбер вакыт шундый мәхәббәт-фәлән берлән мөбтәляләнүемне уйлый да алмый идем. Минем үземне сөяләр иде, мин сөелә идем, әмма, һичбер вакытта: «Йөзене күрергә мохтаҗ булып, яисә синсез ашый да алмыйм, эчә дә алмыйм, бөтен йөзем саргайды» — сүзләре берлән тәгъбир кылырлык сөю минем тарафымнан юк иде. Мин, үзем булса, шул сөю берлә сөясем килә иде. Минемчә, сөю булса шундый булсын, аның хакында һәммә башка эшләр хәтердән чыксын һәм сөюче кеше шул сөюнең генә колы булсын!.. Яшь вакытларда хикәяләрдә укыган бер өрү берлән сөйдерә торган кимперләрнең, бу заманада чыккан гипнотизмның да сөю өчен тәэсире юклыгына бик кәефем китә иде. Кыскасы гына, мин сөелү, бигрәк сөюне никадәр теләсәм дә, гомеремдә булмаячак дип ышанып куйган идем; шуның өчен хатын алу хакында фикерем бөтенләй башка иде. Гомеремдә бер кешене дә сөю ихтималым юкка, киләчәктәге балаларыма ана булырга ярарлык һәм

аларны тәрбия кылырлык, төскә чибәр түгел генә бер хатын алу иде. Мондый хатынны тапканчы эзләячәк идем, аннан ары өйләнәчәк идем. Матурлык-байлыгыны һичбер хисапка тыкмау фикерендә идем.

Менә шулай итеп, школаны да бетердем. Минем бәхетемә каршымы, бәхетсезлегемә каршымы, әллә иттифакый гынамы, минем имтиханнарым бетүдән бераз гына элек мин әтинең вафатыннан хат алдым. Минем тагы бер мәктәпкә кереп уку фаразларым һәммәсе бердән җимерелделәр. Мин теләр-теләмәс әнием берлән сеңелемне карар өчен авылга кайтып, искедәге әти эшене дәвам итәчәк булдым. Шулай итеп, туганнарымнан якын мәктәп иптәшләремне, атадан якын мөгаллимнәремне, җәлладтан яман хәлфәләремне ташлап киттем. Дустлар-иптәшләр берлән күз яшьләре белән күрешеп, гомер буена бер-беремезне онытмаска вәгъдәләр кылып, сөекле Казаннан, бабаларымызның тәхет паеннан аерылдым.

Минем туган йерем өч-дүрт көн парахут, берәр тәүлек тимер юл берлән барырлык озын юл иде. Мин шулай Казаннан кузгалып киттем, парахут өстенә чыктым. Иптәшләрем берлән күздән югалганча яулык, бүрек селкеп сәламләштек. Анлар күренми башладылар. Минем күңелемнән әллә ни нәрсәм өзелеп калган кеби булды. Арлы-бирле парахут өстендә йөри башладым. Бераздан соң үземнең парахут кузгалганчук эчәсем килгәнлегене исемә төшереп, ул вакытта да сусавым кайтмаганга, үз урыныма, икенче класска чәй эчәргә төштем. Бу чәй янында иптәшләремнән берсе дә булмаганга, бу чәй миңа иптәшләремнән тәмам аерылганлыгыма инандырды. Никадәр эчәсем килсә дә күп эчә алмадым, тиз генә парахут өстенә чыктым.

Парахут бик матур йердән бара иде, бер як урман, икенче як бик киң сахра иде. Кояш түбән төшә башлаганга, көн эссесе кайткан иде. Парахут өсте тып-тын иде. Арттагы чак-чак иткән акчарлак тавышлары гына парахуттагы тынычлыкны бетерә иде. Сахра ягында бер көтү яткан иде. Аннан бер-ике чакрымда гына бер мөселман авылының яшелгә буяган манарасы күренеп тора иде. Бу манара акыртын гына төшкән кояш нуры берлән ялтырап гаҗәп бер күренештә иде. Манара очындагы гөмбәзе ялт-йолт итеп күз нурыны ала иде.

Бу авылга караган саен карыйсы килә, караган саен күңел рәхәтләнә иде. Парахутның өстендәге кешеләр дә табигатьнең шул ләтафәтенә хәйран булып карап баралар иде.

Парахут өстендәге кешеләр арасында ике чибәр гене киенгән мөселман хатыннары һәм дә марҗалар арасында калфагына башка киеме аурупача киенгән бер кыз бар иде. Мин күргәндә бу кыз марҗалар берлән русча сөйли иде. Мин буны күргәч тә русча сөйләвенә гаҗәпкә калдым. Белмәгән булып кына яннарыннан әйләнә башладым. Теге хатыннар мин яннарына бара башлагач бер күзләрене, ярты битләрене калын шәл астына тыктылар да берсенә-берсе төртә-төртә сөйләшә башладылар. Бу кыз, гүя минем барлыгымны күрмәгән кеби, сүзене бүлмәде һәм кыяфәтене үзгәртмәде. Бунын бу эше мине тагы таңга калдырды. Мин бер-ике әйләндем дә, анларга ерак түгелрәк кенә бер урынга утырып, сүзләрене тыңламакчы булдым. Озак үтмәде, иптәш марҗасының берсе торып китте, берсе миңа карап: «Пристань еракмы?» — дип сораша башлады. Сүз иярә сүз китте, без байтак сөйләштек. Теге кыз сүзгә бер дә катышмады. Марҗаның кая барасыны сораштым, безнең якка бара икән. Шуннан соң ул марҗа китте. Бу кыз берлә сүз башлар өчен: «Син дә бунын берлә барамсың?» — дидем. (Мин ул вакытка кадәр кемне күрсәм дә «сез» дия идем, буңар ни өчендер «син» дидем.) «Мин тимер юл берлә дә китәм, әле минем барасым күп, «...»гә барам»,—диде. «Ник барасың?» — дигән сөалемә кыз: «Ирем янына барам, ул анда управляющий булып тора»,— дип җавап бирде. Мин сорадым, ул җавап бирде, ул сорады, мин җавап бирдем. Шулай итеп, бер-беремез берлән таныштык. Ул Казан кызы икән. Ире «...» дән илле-алтмыш чакрым йердә торганга, анын янына бара икән. Мин Казандагы танышларымны сораша башладым. Бәгъзесене белсә дә, күбесене белми иде. Казанда һәммә хатын арасында өйдән-өйгә сөйләнеп йөри торган Казандагы яңа хәбәрләрне дә сораштым. Берсене дә белмәде.

Фәлән байның бөлүене, фәлән бай хатынының иргә китүене, фәлән хәзрәтнең бер ике-өч көн югалып торуыны, яңа «аләт» берлә өшкерүче

ишанның кыйссаларыны безнең Казан хатыннары су кеби эчә торып, бу Казан кызының берсеннән дә хәбәре юкка гаҗәпкә калдым. Ул гаҗәпсенүемә каршы: «Мин андый сүзләрне тыңлый да белмим, тыңласам да бер колагымнан кереп, икенче колагымнан чыгалар», диде. Русча белүене сорадым: «Бераз укыдым, күп укый алмадым. Таныш русларымызның кызлары бар иде, шунлар берлә бергә уйнап үстек, шуның өчен сөйләргә бер дә аптырамыйм»,— диде. Без бунын берлән әллә нинди сүзләргә кереп киттек. Казан халкының гайбәтчәнлегене, һавалылыгы, хатыннарының әдәпсезлегене ул: «Татарлар шулай итәләр!» — дип кенә, оста гына, көлеп кенә куя гына бирде. Безнең шикелле кешеләргә безнең халык арасында хатын-кыз берлән сөйләшү нинди авыр икәнлеге һәммәмезгә мәгълүм инде. Шуның өчен сирәк кенә тугры килгәндә, һәммә кеше, җае тугры килгәч, файдаланмакчы булып, әллә ниләр дә булып китә. Мин дә бу кыздан үземчә файдаланмакчы булып, үземнең иң беләсем килгән Казан хатын-кызының тормышы тугрысында сораша башладым.  Бик ачык иттереп сөйләп бирде.

Хатын-кызларның качуы-качмавы хакында сөйли башладык. Бердә курыкмаенча гыйффәт өчен качу берлән качмауның аермасы юклыгыны, бигрәк кача торган хатыннарга аз гына ирек булса, теләсәләр ни эшләргә хәзерлекләрене мисаллары берлән исбат кылды. Мин дә: «Безнең халыктагы хатын-кызның ул кадәр аерым торуы ирләремезнең табигатьләренең бозылуларына сәбәп була»,—дидем. Мәсәлән, ирләрдәге тупаслык, катылык, кальби эшләрне аңламау, хатыннар берлән катышмау, сөйләшмәүдән идекене, Аурупа халкында башкачалыгы берлән исбат кылдым. Ул: «Менә ирләрнең сөйли белмәүләре дә шуннан булырга кирәк. Безнең халык бер дә сөйли белми бит, үз эшеннән бераз сөйли дә тик утыра. Менә сезнең (ул миңа һаман «сез» дия иде) белән кайчаннан бирле сөйлимез, сүз һаман бетми, анлар берлән кая болай сөйләргә? Йә сүзе бетә, бетми икән, начар сүзгә бора, ләгънәт суккан бер халык инде»,—диде.

Без шул сүзләрне сөйләгәндә ике кеше парахут өстенә чыктылар. Берсе картрак, берсе яшь кенә бер егет иде. Яшенең өстендә яңа мода киемнәр булса

да, чалбар кимәгән иде. Кулында зур чиккән намазлык иде. Бу кешеләр безнең янгук килеп бик тыңлап торсалар да, без әллә нинди уку, наданлык мәсьәләләренә кереп киткәнгә, аңламаганнар булырга кирәк, бераз авызларыны ачып торганнан соң, намаз укырга тотындылар. Теге хатыннар да парахут өстенә чыгып безгә карап төртеп-төртеп сөйли башладылар. Ахырысы безнең шулкадәр озак сөйләшүемез гаеп күренгәндер. Шул сөйләү берлән без кичке сәгать унбергә кадәр утырыштык. Ахырдан ул: «Миңа төшәргә вакыт»,— дигәч, мин: «Исемеңне сорарга ярыймы?» — дидем. «Ник ярамасын?» — дип исемене, фамилиясене, кемнәр икәнлегене һәммәсене әйтте. Исеме Гөлгыйзар иде.

## II

Бу заманда төрле фикерләр тараллыгы һәркемгә мәгълүмдер. Күп кешеләр иң яңа фикерләрне кабул итдекләре кеби, бәгъзеләре иң иске әүһам вә хыяләттән дә котылганнары юктыр. Уртача фикерләрне кабул итүчеләр вә аның тарафдарлары һәрвакыт бик аз күрелдеке кеби, безнең заманада да ифрат, тәфрыйт тарафдарлары һәр эштә күзгә ташланудa иде. Мәсәлән, бәгъзе кешеләр дөньядагы һәр вөкугатка сәбәбе мадди эзләп, бәгъзесенә хәтта табып, мәгънәвияткә инкяр кылалар иде. Вә бәгъзеләр ат туктау, мәче битен юу кеби эшләрдән дә әллә нинди мәгънәви серләр чыгарган булып, һәрнәрсәнең сәбәбе маддисыны инкяр кылыр дәрәҗәсенә җиткәннәр иде.

Башка кешеләр кеби мин дә әүвәлдә маддиуннар җөмләсеннән идем. Чөнки минем яшь, бозылмаган димагымны мәгънәвиуннар юк нәрсәләрдән юк мәгънәләр чыгарып, эчемне пошырып бетереп, бик туйдырганнар иде. Шуның өчен мин маддиуннан идем.

Минем таныш хатынымның исеме Гөлгыйзар булуы, мине көчләнер-көчләнмәс әллә нинди алдан сизүләргә, күп эштә әллә нинди мәгънәви

нәрсәләр барлыгына ышандырган иде. Чөнки минем дөньяда иң яраткан исемем булса — ул да Гөлгыйзар иде. Гөлгыйзар дигән сүз минем тәнемә әллә нинди бер хәрәкәт бирә иде. Шул исемдә һәрвакыт әллә нинди бер үзлек сизә идем. Гөлгыйзар! Гөлгыйзар! Вакыйгъда бик матур исем!.. Якыннарымнан берсе бервакытны яшь чагында бер пожарда бер өйне күреп, шул өйдә торырга бик кызыкдыгыны, һәм шуннан сон, дөньяда торуыны уйлаганда, һәрвакыт шул өйдә торыр кеби булып, ничә еллар йөргәннән соң, шул йортның кызыны алып, шунда тора башлавыны сөйләгәндә «иттифакый» гына дигән булсам да, Гөлгыйзарның Гөлгыйзар булуы мине галиме руханиның барлыгына катгый ышандырды. Мәгънәвиуннарның әллә нинди дәлилләренә һич ышанмаган кеше парахуттагы бер кызның: «Исемем Гөлгыйзар» дигән сүзе берлән буннан йөз ел элек мәсләгем шул кеби ышандым. Урыныма кереп яткач, бик озак уйлап яттым. Буңарчы гомеремдә Казан халкы арасында Гөлгыйзар дигән исемне һич ишетмәенчә, кальбемнән Гөлгыйзар дигән исемгә бер якынлык сизеп йөрүемне, бүген танышкан кызымның татар галәмендә буңарча күренмәгән фикердә, тәрбиядә, мин ярата торган тарызда булып, исеменең Гөлгыйзар булуыны мәгънәви бер сергә багышламый нигә багышлыйм?..

Бик озак әллә нинди фаразлар берлән башымны әйләндереп, бер-ике мәртәбә тагы Гөлгыйзарны күрә алмаммы дип тышка чыгып йөргәннән соң йокыга киттем. Төшемдә артык нәрсә күрмәдем: әниләр, Гөлгыйзар, әллә нинди бер ят ир генә төн буена күз алдымнан китмәделәр. Иртә берлән озак кына йокларга теләсәм дә, йоклый алмадым. Шуның өчен иртүк торып парахут өстенә чыгып йөри башладым. Минем шикелле бер уй берлән йоклый алмый торган, һәм киләчәктәге станциягә төшәргә хәзерләнә торган кешеләргә башкалар һәммәсе йоклыйлар иде. Мин, менә торалар, менә торалар дип, һаман көтә идем. Анлар һаман йоклыйлар иде. Ахырдан, парахут кычкырса, уяныйрлар фикеренә килдем. Киләчәк пристаньга йетүне шулкадәр көтә идем, һич әйтеп бетерү мөмкин түгел.

Пристаньга килеп йеттек. Анлар һаман юк. Минем иптәшләрем парахут тавышына уянып, парахут кузгалгач, чәй эчәргә хәзерләнә башладылар. Мин

дә, эш юктан эш булсын дип, анлар берлән чәй эчтем.

Шуннан соңмы? Шуннан соң, минем көтә торган сәгадәтле минутларым килеп йетте — Гөлгыйзар, торып, парахут өстенә чыкты. Мин бик тиз янына барып саулык-сәламәтлек сораштым. Шулай итеп, бетмәс-төкәнмәс сүз башланды. Көн бик эссегә күрә, Гөлгыйзар эссе сугар, куркам, дип, төшәчәк булды. Мин аңар кальбән разый булмасам да, бер эш эшләр хәл юк иде. Мин, уйлап табып, беренче класска кереп утырырга чакырдым, ул да разый булды. Ләкин һичбер урын булмаганга, без беренче класс башында күләгәдә генә сөйләшә башладык. Ни сөйләшкәннәремез хәзердә онытылган инде. Ләкин Гөлгыйзарның кыяфәте, сөйләүләре, күзләрене ачып кына көлеп йебәрүләре, мин күрмәгәндә күзләрене бик тутырып-тутырып миңа караулары һаман күңелемнән чыкмый. Бәгъзе кешеләр дөньяда сәгадәт юк-фәлән дип сөйләсәләр дә, кайсылары язсалар да, бәгъзеләре шуңар ышанып йөрсәләр дә, мин шул сәгатьләрдә бунларның фикерләренең дөрест түгеллегене белгән идем — чөнки бу вакытта мин мәсгуд  идем. Гөлгыйзар бераздан соң: «Мин класска төшеп менәм»,—диде. Мин дә, икенче кат чыгып-чыкмавыны сорап, класска кергәч тә, чыгып китү оят булыр төсле булгач, эш берлән кергән булып, кулыма китап тотып чыктым. Гөлгыйзар берлән юлда очраштык. Баягы урынымызда бер ике-өч сәгать сөйләшкәннән соң, мин аны аш ашарга чакырдым. Гөлгыйзар, яхшы түгел-фәлән дип тартынмаса да: «Теге татарлар һаман карап кына йөриләр»,—дип, минем берлән бергә ашарга тартынган кеби булды. Минем бик теләвемне белгәч, Гөлгыйзар иптәш марҗасы берлән киңәш итешеп, икесе дә ашта булырга вәгъдә бирделәр. Мин аш хәзерләргә куштым һәм озакламаенча без беренче классның аш өстәленә утырыштык. Мин, Гөлгыйзар берлән кара каршук булмаса да, каршырак утырган идем. Ашлар килгәнчә тагы сөйләшеп утырдык. Бу мәҗлестә мин үземне Гөлгыйзарга тагы якынрак кеби сизә башладым. Гөлгыйзарның минем берлән бертуктамаенча сөйләве мине тагы авызландыра төште. Аш килгәч, мин ашлар бүлдем. Марҗа да сүзгә катышты. Гөлгыйзар күзене тутырып ачып кына көлә-көлә сөйли иде. Аш уртасында гына ул, миңа күзене тутырып карады да, көлебрәк кенә: «Сез

мине озатырга барамсыз?» — диде дә, кызарып китте. Ул һәрвакыт әһәмиятле зуррак бер эш эшләсә яки зуррак бер сүз әйтсә, күзене тутырып ачып бераз миңа караганнан соң әйтә иде. Гүя, шулай күзене зур ачып, ул эшнең артыны-алдыны карый иде дә, ничек буласыны күреп бетергәннән соң әйтә иде. Аның шул күзене тутырып ачуыны мин шулкадәр ярата идем, әгәр Гөлгыйзарда шул булмаса, белмим, киләчәктәге сөйләнәчәк эшләр Гөлгыйзар берлән безнең арада йә булыр иде, йә юк иде. Шул вакытта аның кыяфәте дә үзгәрә иде, күзенә дә дикъкать, төсенә дә җиддият әсәрләре чыга иде. Мин Гөлгыйзарның бу сүзенә гаҗәпкә калдым. Әгәр аның, үзе ни тели шуны эшли торган, үзенә үзе баш хатын икәнене, һәммә эшене уйлап бетереп эшләвене буңарча сөйләүләремездән белмәгән булсам, минем берлән болай сөйләүләрне бер төрле яшьлек фикерләренә яки әхлаксызлыгына багышлар идем. Ләкин Гөлгыйзарны күргән кеше, Гөлгыйзарны белгән кеше аның андый фикерләрдән мөкатдәс икәнлегендә һич шөбһә кылырлык түгел иде. Гөлгыйзар шундый бер хатын иде, аның берлән өч ел бергә дуст булып торып әхлакка мохалиф бер эш эшләмәү бик ансат иде. Чөнки аның күз карауларының, сүзләренең төбе һәрвакыт әхлаксызлыкка дошман булуыны, үзенең аннан бер дә ләззәт алмавыны белдерүдән башка, кирәк урынында ачык итеп әйтүдән дә бер дә куркырлык түгел иде. Мин озак уйлап тормадым: «Сиңа мөмкин булса, разый» — дидем. Ул тагы күзене ачып җитди бер рәвештә! «Ярар, барырмыз! Яме!» — диде. Моның бу сүзләре әллә нинди өметләр, әллә нинди уйларның нәтиҗәсе икәнлеге Гөлгыйзарның кыяфәтеннән, авыз ачуларыннан билгеле иде. Ләкин «Гөлгыйзар ни уйлый? Мин ник барам? Анам янына кайчан кайтырмын? Бу эшләрдән ни чыгар?» сөальләренә минем башымда бер җавап та юк иде. Мин анларны уйлый да алмый идем һәм уйлыйсым да килми иде. Ни булса ул булыр дип, эшне үз уңаена салган идем. Эш минем уем буенча йөрмәенчә, бәлки уем эш артыннан йөри иде. Эш арасында үзем яраткан ашларны: «Гөлгыйзар, менә монысын! Менә тагы аша! Бер тәрилкә генә бүлим, фәлән» — дип кыстаганга, Гөлгыйзар: «Әйем!» — дип кенә җавап бирә иде. Гөлгыйзарның бу сүзе, аңар бер хатын гына дип карый

торган кешегә аның балалыктан яңа гына чыгуыны белгертсә дә, миңа бөтенләй икенче хисләр бирә иде, Гөлгыйзарны сөйдергәннән сөйдерә иде. Шул «әйем!» дигән сүзне әйткәндә, Гөлгыйзар үзе дә мәгъсум бер бала төсле булып китә, миңа тагы матур, тагы сөемле күренә иде. Мин шул сүзне әйттерер өчен аш килгән саен аны кыстый идем; ул тагы: «Әйем!» — дия иде. Аштан соң аңар укырга вак-төяк хикәя китаплары бирдем. Буннан соң без бу елларда чыга башлаган китаплар тугрысында сөйли башладык. Аның әдәбият хакында бер дә мәгълүматы юк иде. Мин аңар шундый әдәби китапларның кешене ачуыны, романнар, хикәяләрнең укый белеп укыган кешенең холкыны төзәтүене сөйләдем. Ул минем сүзләремне бик ихлас берлән тыңлады: «Анларны кемнәр яза соң?» — дип сорады. Мин шундый китаплар язуны безнең халык бик кечкенә эшкә санаса да, аның зур эш икәнлегене, бер кыска гына әхлаклы, кирәгенчә язылган хикәянең файдасы егерме сарфы гарбинең файдасыннан, кырык тәҗвиднең файдасыннан ар- тыклыгыны бәян кылдым. Һәм дә, аңар ачыграк булсын өчен, хәзер безнең заманда язу белгән бер кешенең бер тәҗвид язуыны һәм «Шәрхе Габдулла»сы бар бер кешенең үзенчә бер сарфы гарби язуыны, «Әсәре сәлим сабит» дигән төрек җәгърафиясе иясенең бер җәгърафия язуыны да сөйләдем. Гөлгыйзарның аңар исе китте: «Ник аның кирәген генә язмыйлар?» — дип сорады. Аның башы бер дә бозылмаганга, андый табигый булмаган эшләргә гаҗәпкә кала иде. Ул минем китапларымны алып укырга тотынды. Мин дә кулымдагы русча бер китапны укый башладым. Шул уку берлән без бер-беремездән өч-дүрт сәгать аерылып тордык.

Өч-дүрт сәгатьтән соң мин чыгып барганда, Гөлгыйзар кулына китап тотып ишектән карап тора иде. Мин аны күргәч: «Чыгамсың?» — дип сорадым. Ул: «Әйдә үзеңез кереңез, монда бер кеше дә юк»,— диде. Мин кердем, Гөлгыйзардан китап тугрысында сораша башладым. Ул миңа карап: «Бу китапны миңа биреңез! Ядкареңез булыр» — диде. Мин: «Биргәндүк сезгә бүләк булсын дип әйттем», —дидем. Ул, миңа рәхмәт укып, китапны алып куйды. Үзе чыгарга хәзерләнә башлады. Бер-ике минуттан без тагы парахут

өстенә чыктык. Ул хикәядә укыган бер кызның бәхетсезлеге тугрысында сөйләшә башладык. Мин, уйсыз эшләрдән нинди эшләр чыга, һәрвакыт эшнең әүвәлене-ахырыны уйларга кирәклегене сөйләдем. Ул исәпләп торды да: «Тәкъдир шулай булгач, нишлисең! Кеше ничек уйласа да, нинди эш эшләсә дә, язмышыннан котыла алмый » — диде. Мин: «Коры тәкъдир генә түгел, кешенең үз ихтыяры да бар, кеше ни теләсә, шуны эшли ала»,— дидем. Ул: «Анысы шулай, ләкин кеше ник ахырдан үзенә зарарлы эшне тели? Менә бу хикәядәге кыз ник теге егетне сөйгән?.. Аны ул үз ихтыяры берлән сөйгәнме?.. Юк, тәкъдирдә шулай язган булган. Ул кызга шулкадәр авырлыклар күрергә язмышындук булган, шуның өчен ул авырлыклар күргән. Ихтыяр дисез! Әгәр ихтыяр булса, кешеләр начарлыкны ихтыяр кылалармыни?.. Юк, һәммә кеше яхшыны ярата, һәммә кеше яхшыны тели. Ләкин берәүгә яхшы дигәне начар була, начар дигәне яхшы була», — диде. Мин: «Синеңчә бер дә ихтыяр юкмы? Менә мин хәзер сине суга алам, сине кыйный алам; ләкин боларның зарарлы икәнене белгәнгә, эшләмим», — дидем. Ул: «Мондый кечкенә эшләрдә мөмкин. Монда әүвәле-ахыры күренеп тора. Менә шундый эшләр бар, анда һич кешенең үзеннән түгел. Бер кыз бер егетне сөя, бер хатын иреннән аерыла. Бунлар, шул эшләре берлән үзләренә зарар итсәләр дә, мин, үзләреннән, дия алмыйм. Шуның өчең мин һәммә эшкә тәкъдир шулайдыр дип кенә карыйм, һәм мин яңа бер эшнең килеп чыгуына бер дә исем китми»,—диде.

Бу сүзләрне Гөлгыйзар шулкадәр ихлас берлән сөйли һәм үзенең фикеренә шулкадәр ышанган иде, аны җитмеш төрле дәлил берлән бу фикереннән кайтару мөмкин түгел иде. Һәм аның шулай һәр эшкә «тәкъдир» дип каравы һәр эшендә дә билгеле иде. Дөньяда булган нинди зур бәла башына килсә дә, ул артык кайгырмаенча, «тәкъдир шулай» дип калачак иде. Мин дә артык сөйли алмадым. Чөнки һәр сүзе миңа үзенә бертөрле тәэсир кылганга, үзем дә чак кына бөтенләй Гөлгыйзар фикеренә кермәенчә калган идем. Моннан соң сүзләремез фамилия сәгадәте, мәхәббәт кеби эшләргә борылды. Гөлгыйзар мәхәббәт тугрысында күп сөйли алмады; һәм сүзләреннән, кылынышларыннан бу мәсьәлә тугрысында бик сөйлисе килмәве билгеле иде.

Белмим, мәхәббәт дигән сүз аңар бер- бер кешегә булган үзенең мәхәббәтене исенә төшерде, белмим, мәхәббәт төшерергә тиеш булган кешегә мәхәббәте юклыгыны хәтеренә китерде? Фамилия сәгадәте тугрысында Гөлгыйзар биөмиданә, бирафиганә: «Дөнья оҗмах түгел, әллә нинди рәхәт булмый», — иде. Ләкин минем фикерем бөтенләй башка булганга, фамилия сәгадәтенең барлыгыны һәм дөньядагы тормышның фамилия сәгадәте берлән генә тормыш төсле булуыны, фамилия сәгадәтенең ир берлән хатынның бер-берсенә тугрылыклары һәм ышанулары берлән бергә булуларыны озын бер дәрес кеби сөйләдем. Гөлгыйзар һәммәсене аңлады, һичберсенә могаризә кылмады. Ләкин тагы күзене зур итеп кенә ачып: «Булмый ул, берсенә кызык булган нәрсә икенчесенә рәхәт бирми, берсенә рәхәт биргән эш тә икенчесенә кызык булмый!.. Хатыны театр яратыр, ире яратмас, шундый бик күп булырга мөмкин», — диде. — «Минемчә, никях мәхәббәтсез булырга ярамый, мәхәббәт булды исә, берең сөйгәнне икенчең дә сөяргә кирәк; береңә рәхәт бирә торган эшне икенчең дә шатланып эшләргә кирәк. Аннан соң, өйләнүдә ике як та берсенең холкыны берсе белергә кирәк, ул вакытта андый эшләр булмый», — дидем.

— Безнең туйларда ничек ул кадәр белергә кирәк, бездә киявеңнең төсене күрә алсаң да ярар иде... — диде.

— Алай булса да бездә кызлар гадәттә күп егет күреп күңеле төрлеләнмәгән булганга, ирләрене бик сөяләр, — дидем.

— Әйе, бик сөяләр!.. — диде.

Бу сүзләрне Гөлгыйзар әллә нинди бер тавыш берлән әйтте. Бу сүзләр аның авызыннан гына чыкмады, йөрәгеннән чыкты. Бу сүзләрне әйтүеннән үк Гөлгыйзарның үзе тугрысында икәнлегене белдем дә, ни әйтергә аптырап, бер-ике минут дәшмәенчә тордым. Ул да минем аңлаганымны белгән булырга кирәк, чөнки бер сүз әйтми тора иде. Мин сүзне иренә бормакчы булсам да, база алмадым. Андый сүз тапмаган вакытта кешеләр үзләренә иң якын, икесенә дә бик мәгълүм нәрсәләрдән сөйли башлыйлар. Күп вакытта һавадан башлана, бара торган табигатькә барып йетә, бара-бара кирәгенә бора-бора

гыйшыкkка да барып йетәләр. Без дә һавадан башладык. Сикерә-сикерә гыйшыкны да сикереп. Гөлгыйзарның иренә барып йеттек. Мин: «Ирең кем, нинди кеше?» — дип сораша башладым Ул, бер дә әүвәлге рәвешене бозмаенча, гүя бик гади нәрсә хакында сөйләгән кеби генә ире хакында сөйләде. Моның сүзенә караганда, ире йомшак кына, фикерсезрәк кенә, гакыллы гына, салкынчарак кына бер татар малае иде. (Моның бу тәгърифе баягы сүзләренең үзе хакында әйтелгәнене тагы белгертте.) Бара-тора безнең дә сүзләр мәхәббәткә йетә башлагач, ул авырсыныбрак сөйли башлады. Ул һәммә сүзне әйткәндә: «Йә инде! Анда ни булсын!» —дигән кеби генә сөйли иде.

— Ирең нинди фикердә, хатын-кыз хакында ни уйда? Хәзер безнең шулкадәр озак сөйләшеп барганны белсә, ачуланыр идеме? — дидем.

— Ул бик ачуланыр иде дә, мин аннан курыкмыйм, ул бик көнче, мине кыз вакытымда бер егеткә сораганнар иде, әнә шуннан ла көнләп йөдәп чыга, — диде.

— Ул синнән курыкмаса, син аннан курыкмасаң, ул нинди тормыш булыр? Сез бер-берeңездән курыкмасаңыз да, бер-берeңезне ригая кылышырга кирәк, — дидем.

– Ул миннән курка, минем алдымда бер сүз сөйли алмый. Мин аннан бер дә курыкмыйм, мин яшьтән үк үзем теләгәнне эшләргә өйрәнеп үскән. Менә әле дә, сез парахутка кергәч тә, күңелемнән: «Сезнең берлән танышасы иде»,— дидем һәм таныштым; менә хәзер бернигә карамый сөйләшеп барам. Анларча бит бу гаеп инде, нишлим соң?..— диде.

Мин бу сүзләрдән Гөлгыйзарның үзенең язмышыннан разый түгеллекене тәмам белдем. Ул миңа шулкадәр кызганыч күренде, һич әйтеп бетерә алмыйм. Мин аңар анык тугрысыннан сөйләмәгән төсле генә булып, бала булгач, мәхәббәт артуларыны, тора-тора да якынлык артуыны сөйләдем. Ул бик иренеп кенә: «Бунысы тагы нәрсәгә инде? Аны сөя алмаенча тора алмаммыни?» — дигән кеби генә тыңлый иде. Бераздан соң мин аны чәй эчәргә чакырдым. Беренче класска эчәргә керсәк тә, урын булмады. Ул: «Ярар

инде, мин иптәш марҗам янында эчәрмен», — диде. Мин бер дә аннан аерыласым килмәгәнгә, ничек булса да  урын эзләргә тотындым. Һәм дә иптәшләремнең каютыны сорамакчы булдым. Озак үтмәде, алардан рөхсәт алып, каютка чәй хәзерләттем. Ул класска кергәндә иптәше кичке аш китерергә кушканга, анларның аш ашауларыны көттем. Аштан сон Гөлгыйзар минем яныма чәй эчәргә керде. Гөлгыйзар, кергәч тә, һич эчәсе килмәвене, фәкать сүзендә торыр өчен генә керүене әйтте. Ләкин ни өчендер, ул керүеннән разый түгел төсле күренә иде. Миңа да шул керүләр әллә нинди зур эшләргә сәбәп булыр кеби беленә иде. Хасыйле, шул минутта безнең икемезнең дә уйларымыз башкарды. Рәтләп сөйли дә алмадык.

— Татарлар шикләнерләр, ни дип монда кердек? Әйдә өсткә чыгыйк,— диде.

Мин элгәре: «Бернәрсә дә булмас», дисәм дә, берәр чынаяк чәй эчкәч тә, аның уена разый булдым, һәм бик тиз парахут өстенә чыктык. Без чыккач та парахут пристаньга туктаган иде. Төн бик караңгы иде, сирәк-сорак кына болыт астыннан күренгән йолдызлар гына елт-елт итеп кенә китәләр иде. Гөлгыйзар пристаньга да чыкмады. «Әллә нәрсәгә кәефем китте, мин чыкмыйм»,— диде. Мин ялгыз чыктым, бик биек тау янындагы шаулап ага торган чишмә тавышына сандугач тавышлары кушылып, е953рактан гына ишетелә торган эт тавышлары берлә, әллә нинди манзарәләр күрсәтүдә иде.

Көн җилсез иде. Минем күнелемдә, һәммә тамырларымда, һәрбер әгъзамда әллә нинди, бер кәефсезлекне көткән кеби бер авырлык бар иде. Минем иптәшләрем шарык-шарык көлә-көлә әллә кайдан урман арасыннан төн караңгысында күрмәенчә чәчәк дип кайсысы кычыткан, кайсысы әрем кеби үләннәр җыеп килделәр. Мин бик кәефсез булмасам да, иртәнге Габдулла түгел идем. Мәгълүм бернәрсә тугрысыннан уйларга белмәсәм дә, уйларым һәр эшнең ямьсез ягына китә, уйлаган саен төрле ямьсезлекләр килеп чыга иде. Парахут киткәч, мин кичке ашны ашап кереп яттым. Әллә нидән кандала базына төшкән кеше кеби әүвәле йоклый алмаенча, йоклагач та уяныш-уяныш йөдәп чыктым. Төшләремдә вак-төяк этләр күреп саташып беттем. Иртәгесен

иртүк торып парахут өстенә чыктым. Озак үтмәде, иптәшләр дә тордылар һәм чәй дә эчтек. Мин тагы әүвәлге кеби Гөлгыйзарны көтә башладым. Көндәге вакыт йетте, бераз үтте дә — Гөлгыйзар һаман юк иде. Мин ни эшләргә белмәенчә йөргәндә теге маржа яныма килеп утырды, һәм дә миңа Гөлгыйзарның авыруыны, бик кәефсезлегене сөйләде. Мин: «Нинди авыру? Нинди кәефсезлек?» — дип сорадым. Маржа кичәге безнен каютка керүне теге татарларның белүләрене һәм Гөлгыйзарга бик зур ифтира кылуларыны, һәм дә ире берлән танышлыкларыны әйтеп, аңар хат язуларыны, Гөлгыйзарга башкача да нәсихәтләр сөйләүләрене ап-ачык иттереп бәян кылды. Бу сүзләрне ишеткәндә, мин үземнең нишләгәнемне белмим, ләкин теге марҗаның: «Нишлисен? Ник ул кадәр агардың?» — диюеннән һәм кулымдагы китабымның төшүеннән, хәзер генә, ахры бик каты эчем пошып киткәндер дип уйлыйм. Бу сүзләрдән соң мин үземнең ни эшлисемне һич белмәдем. Яз көнендә карлар, бозлар берлән буылган су кеби, минем уйларым да буылганга кайсы яктан уйларга да, нинди эш эшли башларга да белми идем. Теге маржа озак кына карап торганнан сон: «Юкка кәефсезләнмәңез, бер ни дә булмас», — диде. Ахырдан мин марҗага карап: «Миңа ул татарлар берлә сөйләшергә тиеш. Мин бу эшне болай гына калдыра алмыйм... Бу сүзләрне Гөлгыйзарның ире ишетсә, ни булыр?! Гомерлек бәхетсезлек булу ихтималы бар бит? Шул бәхетсезлеккә мин сәбәп була алмыйм! Ни булса булыр, мин бу эшне болай калдыра алмыйм! Моңар кечкенә генә иттереп карый алмыйм! Мин һичбер вакытта минем өчен яисә минем сәбәпле бер кешенең җәзалануыны йөкли алмыйм. Мин хәзер ул татарларны күрәм. Сез Гөлгыйзарга әйтеңез! Мин аны һәммә бәхетсезлекләрдән сакламакчы булам!» — дидем дә чыгып киттем. Бераз киткәч тә мине теге маржа чакыра башлады. Мин килдем. Маржа: «Гөлгыйзар, әйтмәсен, дип әйтә», — диде. «Алай булса, мин хәзер Гөлгыйзарны күрергә тиеш»,— дидем. Ул һәммәсене булдырачак булып вәгъдә бирде һәм берәр сәгатьтән соң, хатыннар бүлмәсендәге һәммә хатыннан рөхсәт сорап, мине чәй эчәргә керттеләр. Минем йөрәгем леп-леп сикерә иде. Гөлгыйзарны ничек күрүемне, ниләр сөйләвемне һич уйлап бетерә алмый

идем. Төрле яктан уйлап карасам да, күз алдыма Гөлгыйзарның сәгадәтсезлеге килгән кеби, киләчәктәге ире берлән булачак тавышлары колагыма ишетелгән кеби чыңылдап тора иде.

Ләкин бик күп уйладым, бик күп исәпләдем, бу хәлдән котылырга һич җай таба алмадым. «Йә, берни булмаган ич! Гөлгыйзар берлән ире арасында ни булса да мин гаепле түгел. Татарлар шулай сөйли, имеш! Хакыйкатьтә бу эштә һич бер кеше гаепле түгел!» — дисәм дә, күңелемнең икенче кырыеннан бер тавыш: «Әйе, сине хәзер хөкем берлән гаепләп булмый, син нәфселәмердә гаепле дә түгелсең, ләкин нәфселәмер үзе дә хакыйкатьтә истиляхи гына нәрсә, дөньяда нәфселәмердә «нәфселәмер» үзе дә юк. Татарлар Гөлгыйзарга гаеп исбат кылалар, ул гаеплеме? Син гаеплеме, түгелме? Ул шуның өчен никадәр хәсрәтләр күрергә тиеш!» — дия иде.

Мин кемне гаепләргә дә белми идем. Үземне гаепләргә мөмкин түгел иде. Чөнки вөҗданым гаепсезлегемне әйтеп тора иде. (Минем һәрвакыттагы хакимем — вөҗданымдыр.) Гөлгыйзарны гаепләргә тагы мөмкин түгел. Тагы нидә?.. Нинди гаеп?.. Кемгә зарар булган?.. Шуларны һичбер аңлый алмый идем. Бер хатын берлән сөйләшеп бару, чәй эчү, аш ашау, хәтта эчеңнән генә бер-береңне якын күрешү, минемчә, гаеп булу кайда, хәтта макталына торган сыйфатлардан иде. Бу кәефсезлекләр, безнең хәзерге рәхәтемезне югалтулар, киләчәктәге Гөлгыйзарның бөтен тормышыны бозарлык эшләр нидән чыкты?.. Кем сәбәп булды?.. Һич аңлый алмый идем. Ахырдан бу татарларның шул эшкә бик зур җинаять дип караулары, эшне шулкадәргә әвертүе, алай карауларына сәбәп тә — наданлык, фикерсезлекләре, тәгассыбләре икәнлеге исемә төште.

Йа Рабби! Бер тәгассыб бер хатынны ireннән аера!.. Бер гөнаһсыз егетнең гомер буена вөҗданә мөгаззиб булуына сәбәп була!.. Бу нинди эш?.. Бәлки минем күңелем каралганга гынадыр, ләкин мин бу мәсьәләдә ул кадәр әһәмият бирерлек эш таба алмыйм, әмма татарлар шулкадәр әһәмият биргәннәр иде, хәтта бу эшләре өчен Аллаһе Тәгалә хәзрәтләре дә буш калдырмас әле дип, әллә никадәр сәваблар да өмет итәләр иде.

Бунларны уйлап очына чыкмасам да, нишлисемне ачык белмәсәм дә, Гөлгыйзарны нахак йердә рәнҗетүгә һич разый түгел идем. Мин, шундый халәттәге һәрбер хатын-кызга ярдәм итүне һәр кешенең кешелегеннән санаганга, бу эшне һич Гөлгыйзарга аз гына булса да зарарлы булыр дәрәҗәдә калдыру ихтималым юк иде. Шуның өчен бар уйлаганым Гөлгыйзарны бу яман аттан коткару, әгәр аның каршында гаепле булсам, гөнаһымны сатып алу иде.

Шул фикерләр берлән мин алар янына чәй эчәргә кердем. Саулык-сәламәтлек сораштым. Гөлгыйзар кәефсез иде. Төсенә әллә нинди кайгы чыккан иде. Күз карауларында, сүзләрендә башының нинди уйлар берлән мәшгуль икәне күренеп үк тора иде.

— Мин авырыйм, кичә миңа суык тигән, бүген тагы теге татарларның сүзләре бик авыр тоелды, шуның өчен кәефем бер дә юк!—диде. Теге марҗа шуның өстенә:

— Мин сезгә әйтмәдем әле, ул бая бөтенләй һушсыз булды, мин шул татарларның сүзене әйткәч тә ак киндер кеби булып катты да калды, минем үлә дип котым чыкты.  Ярый әле шунда башына, йөзенә салкын су койгач азрак йеңеләйде, — диде. Мин Гөлгыйзарга карап:

— Ул кадәр кайгыру кирәкмәс иде, анлык эш юк,— дидем. Гөлгыйзар:

— Сезнең берлән миңа юк, әнә татарлар ни сөйли, ди. Минем ирем дә— шул татарларның берсе. Ник кичә каютка чәй эчәргә кердең?.. Гөнаһ шомлыгыдыр шул!.. Хәзер миңа бик авыр булыр. Бик көнче ул! Инде нишләргә дә белмәенчә торам. Башымны бик әйләндерә башласа, тотам да аерылам. Кайгыра-кайгыра башым бетте инде. Бәхетем булса, хур булмам әле!..—диде.

— Бер ни дә булмас әле, ул шулай калыр, — дидем. Бу сүзләрне әйткәч, Гөлгыйзар, тагы җитдирәк бер кылыныш  берлән:

— Булмый калмый инде! Булсын!.. Йетәр инде, бик күп эчемә җыеп тордым!.. Күргәч тә барысыны да үзем әйтәм!.. Берсене дә калдырмыйм!.. Өйгә дә хат язам, бик күп чыдадым инде! — диде.

Гөлгыйзарның бу сүзләре, шулкадәр сабыр, гакыллы хатынның һушсыз булулары, шул сүзләрне сөйләгәндәге йөзенә чыккан кызганыч кыяфәте минем кеби хатын-кыз табигатьле, йомшак күңелле, һәр кешенең кайгысыны зур итә торган гадесөле күзлек берлән карый торган кешегә түгел, һәркемне айандырырлык, нинди_каты күңелле кешегә дә тәэсир итәрлек иде.

Мин шул вакытта аңар нинди күз берлән каравымны белмим. Ләкин аның кәефсезлеге минем кәефсезлегем иде, аның хәсрәте минем хәсрәтем иде. Сөйләшкән саен без кайгылар да уртаклашып, уйларымыз берләнә иде. Мин, бераз уйлап торганнан соң, кинәттән генә бер мәсьәләне хәл кылган кеби бер тавыш берлән:

— Һичбер яшермәенчә әйт: иреңне сөямсең, юкмы?— дидем.

— Мин гомеремдә бер кешене алдаганым юк. сезнең кеби кешене ничек алдыйм, сөймим, — диде.

Бу сүзләр Гөлгыйзарның авызыннан ук кеби чыкты. Мин бераз карап торганнан соң:

— Алай сөймәгәч, ничек бардың, Гөлгыйзар? Ничек торасын? Тагы аның янына ничек барасың? — дидем. Гөлгыйзар минем сүземә каршы бик зур сулап кына бик эченнән иттереп кенә:

— Тәкъдир шулай булгач, нишлисең! — диде.

— Бик авыр түгелмени соң, Гөлгыйзар, шундый кеше берлә тору? — дидем.

— Дөресте генә, мин аның берлән торганым юк. Тагы мин аны яратмыйм да түгел, яратам да түгел. Менә ничек әйтим инде? Танымаган кешене ничек күрәсең, мин дә иремне шулай күрәм. Сөямме, сөймимме — һич белмим. Хәзер менә башымда бер бәла бар кеби, әллә нинди, минем һәммә эшемә каршы килә торган бер кеше бар төсле күренә! Мин аның берлән ике атна гына тордым. Аннан соң мине ни чикле алып китәргә теләсә дә, мин бармадым. Менә хәзер үзе дә бик ялынын-ялынып хатлар язгач, әниләр дә бик кыстагач, барырга чыктым,—диде.

Миңа Гөлгыйзар тагы бик кызганыч күренде. Мин бөтенләй

нишлисемне белмәдем, күңелемнән ничек булса да бу бәдбәхетне бу бәладән коткарачак булдым. Һәм дә бу эшләрдән соң минем вазыйфам да аны болай калдыру түгел иде. Хосусән, шул минутларда миңа Гөлгыйзар шулкадәр күренгән иде, һич әйтеп бетерә алырлык түгел. Мин парахуттан соң аерылып, Гөлгыйзардан башка китүләремне курыкмаенча һич уйлый да алмый башладым.

Аккан суга бөя бусаң су тула, эшләргә теләгән бер эшне кылудан тыйсалар, теләү шулкадәр арта, адәмнең һәр куәте шуңар гына борыла. Безнең бер-беремез берлән сөйләшеп йөрүемездән тыймакчы булдылар. Күңелемездә ябылып яткан якынлык гыйшыкка әйләнде. Татарларның шул эшләре аны алардан шулкадәр биздерде, кем ярдәм кылса, шуны гомер буенча онытмас дәрәҗәсенә килде, минем кызгануымны белеп, аның өчен һәр эшне эшләргә хәзерлегемне белеп, теләр-теләмәс миңа күңел баглады.

— Гөлгыйзар! Син мине хәзер шактый беләсең. Белмәгән якларың булса — минем тормышым-фәләнем генә. Мин әнинең бердәнбер угылы. Үземә хәзер бер йорт калды. Авылымызда училище бар, шунда хәзер мөгаллим булам. Болай да без бик фәкыйрьләр түгел. Әни бик яхшы карчык. Ике кечкенә сеңелем бар. Менә мин шунда торачакмын. Минем, күп булмаса да, биш-алты йөз сум акча керерлек урыным бар. Әгәр син теләсәң, мин сине алырга хәзер!—дидем.

Гөлгыйзар урыныннан күчеп утырды. Күзләрене тагы зурайтын карап, бераздан соң:

— Мин кешедән калган. Гомер буена кеше калдыгы берлән гомеремне әрәм иттем димәмсең? — диде.

— Гомеремдә андый сүз әйтмәм. Мин үзем гыйффәтле егет түгел. Минем дә кызлар күргәнем бар. Хәтта мин, үземнең шул көенчә, моннан элгәре: «Ничек гыйффәтле кызга өйләнергә кирәк?» — дип йөри идем, чөнки вөҗданым белән гомерендә бер мәртәбә егет күрмәгән кызга тиң кеше гомерендә бер мәртәбә кыз күрмәгән егет кенәдер. Әмма мин алай түгел, бәлки башка кешеләрдән, кардәш-кабиләмнән булса да ул сүзне ишетергә тугры

килер, анысы алданук белеп торырга кирәк ,— дидем.

— Мин анларның һәммәсене беләм, һичберсенә исем китми, — диде. Гөлгыйзар бу сүзләрне сөйләгәндә бөтенләй башка кеше булган иде. Аның йөзендә, күзендә шатлык уйный башлады. Шулкадәр кәефсез, эшнең шулкадәр кәефлегә әйләнүенә ышанырга да, ышанмаска да белмәенчә минем күземә карый иде. Аның ул күз караулары: «Син шул чикле яхшы кешемени? Миңа шулкадәр яхшылык кыласыңмыни? Мин соң шунлык кеше микәнни?» — дигән кеби була иде. Мин тагы:

— Гөлгыйзар! Минем бу уем сине кызганудан. Мин сине хәзер бу көенчә бәхетсез дип беләм. Тагы бу эш тә килеп чыкты. Әгәр минем бу эшемнән синең хәлең яхшыланыр төсле булса, син гомереңбуена: «Мине иремнән аерды, ай ирем!» — дип кайгырырлык булмасаң гына ярый. Әгәр мин дә, шул элекке ирең төсле сиңа бер «бәла» генә булачак булсам, кирәкми. Чөнки ул вакытта син дә бәхетсез булырга кирәк, мин дә бәхетсез булырга кирәк. Син дөрестене генә әйт, миңа хәзер ничек карыйсың? — дидем.

— Бу чикле сүзләрдән соң, бу эшләрдән соң аны, минемчә, сорарга да кирәк түгел иде. Әгәр сине якын күрмәсәм, мин сиңа шулкадәр сүзләр сөйләр идеммени?.. Мин ирем берлән бу кадәр сөйләп торганым юк иде. Якын күрәм, хәзер дөньяда синнән якын кешем юк!.. Соң син үзең, миңа ул сүзләрне мине кызганганнан гына әйтәсеңме? Әллә тегеләй дә якын күрәмсең? — диде.

— Гөлгыйзар! Хәзер минем күңелемдә синнән башка кеше юк. Миңа гомер дә синең берлән бергә булса гына кызык үтәр төсле күренә. Синең холыкларыңны, кылынышларыңны, төсеңне бик ярattым. Беләмсең, мин син торганны нинди шатлык берлән көтә идем; ул вакытта мәхәббәт икәнене белмәсәм дә, ул чактук мин сине сөйгән, күрәсең! — дидем.

— Алай булса мин синең сүзеңә разый. Ләкин мин ир хатыны әле!.. Ни дип синең берлән кыз вакытта очрашмадым?! Ай бәхетсезлек! Ай бәхетсезлек!.. — диде.

— Гөлгыйзар! Минем теләгем — синең дөньяда рәхәт торуың. Әгәр сиңа ирең берлән тору рәхәт булыр төсле күренсә, мин бер дә көчләмим, мин

бик разый,— дидем,

Гөлгыйзар, минем бу сүзләремнән бераз йөзенә чыкты да:

— Нигә юк сүзне әйтәсең? — диде. Кулына револьвер алып бер кешегә төзәгән кеше кеби игеп, кулыны селкен: «Менә хәзер күземә күренсә, атар идем!..» —диде.

Бу сүзне әйткәндә Гөлгыйзарның йөзенә әллә нинди җиддият чыккан иде. Күзләре: «Бу сүзне мин әйттем!.. Үзем әйттем!.. Кирәк булса, тагы әйтәм!..» — дигән кеби карыйлар иде. Без бу сүзләрне сөйләгәндә янымыздагы марҗалар күзләрене алмаенча безгә карап торалар иде. Без пристаньнан алып кергән җиләкне берәмләп-берәмләп ашый-ашый һаман сөйли идек. Без сүзне озайттык. Тормышның планнарыны төзергә тотындык. Ничек торырмыз, нинди эшләр эшләрмез, минем нинди якыннарым бар, кемнәргә кунакка барырмыз, һәммәсен сөйләдек. Яңадан кайтып, аны хәзер ничек теге кешедән аеру мәсьәләсенә килеп җиттек, төрлечә уйладык. Казанга кайтып китмәкче дә булдык, ул фикер дә ярамады. Ахырдан мин аны «...» га кадәр озатачак булдым. Ире каршы килгән булса, ул шундук һәммәсене әйтәчәк булды, һәммә эшене бетереп, Казанга кайтачак булдык. Әгәр алай булмаса, ире килмәгән булса, анда баргач эшне бетерәчәк булды, һәм миңа телеграмм яки хат язып белдерәчәк булды. Шуның өчен мин аңар үз адресымны бирдем. Ул да миңа адрес бирмәкче булып, корзинадан хат эзләргә тотынды, һәм бераздан иреннән килгән хатны алып миңа бөкләп-бөкләп адресыны күрсәтә башлады. Мин адресны белгәч:

— Хатны күрсәт, —дидем.

— Минем үз серем генә түгел бит, кеше сере дә бар, күрсәтмим, — диде.

— Ярар алай булса,—дидем.

Гөлгыйзар күземә каран торды да, әллә йөземдә берәр үзгәрү күрде дә: «Мә!» —диде. Хатны алып укыдым. Хат бик озын язылган иде. Мәсҗед картларыннан алып Сәрби җиңгәгә кадәр сәламнән соң Гөлгыйзарга гашыйканә язылган иде. «Җаным»ы, «җаиашым»ы — берсе дә калмаган иде.

Ахырдарак кына: «Мине саргайтма! Кил! Ат алдым, арба алмакчы булып торам. Кырларга чыгып йөрермез, бик кызык булыр!»—дигән сүзләре күземә ташланды. Күңелемнән аны кызгандым. Гөлгыйзарга карап:

—Ул хәзер, мескен, нинди шатлыклар берлән син киләсең, дип көтә торгандыр, син бөтенләй ул көтми торган Гөлгыйзар булып барасың! Кара әле ни язган, мескен, бик кызгандым, — дидем. Гөлгыйзар:

— Мин бер дә кызганмыйм, син дә кызганма. Кешене кызганырга ярамый, үзең кызганычка калырсың, — диде.

— Ничек алай була? — идем.

— Менә хәзер син Зәбирне кызгансаң, мине үзеңә алырга тырышмаска кирәк. Сиңа ул бик авыр, менә син кызганычка каласың, — диде.

Дарвин фәлсәфәсенең әсасе булган кагыйдәсене Гөлгыйзардан ишетүемә колагым ышанса да, үзем ышанып ук бетмәдем. Чөнки Дарвин шул сүзләре берлән бөтен дөньяда шөһрәт тотып, галимнең философлары дәрәҗә-сеннән сайалды. Беркая да укымаган, Дарвин дигән сүзне ишеткәне юк бер болгар кызының шул хакыйкатьне кәшефенә һич әһәмият биргән кеше юк!!

Мин тыштан аның фикеренә разый булсам да күңелемнән Зәбирне һаман кызгана идем. Ул минем күз алдымда Гөлгыйзарга карап: «Мине саргайтма! Кил! Ат алдым, арба алмакчы булып торам. Кырларга чыгып йөрермез, бик кызык булыр!» —дигән сүзләрне җылап әйткән кеби күренә иде.

Чәй суына иде, аны җылыта идек, тагы суына иде, тагы җылыта идек. Эчә идек, ясый идек, һаман чәй яныннан тормый идек. Марҗалар кайвакыт, безгә карап арып беткәч, парахут өстенә чыгып керәләр иде, аннан соң китап укырга тотыналар иде, аннан аргач, сөйләшә башлыйлар иде. Без һаман Гөлгыйзар берлән сөйләшә идек, һич арымый идек, һәм вакыт үткәнне дә белми идек.

Гөлгыйзарның йөзенә караган саен минем шатлыгым арта иде. Аның йөзе ачык, шат, мәсгуд, караган саен карыйсыны китерә иде. Авызы ябылмаенча һәрвакыт елмаеп тора иде. Күзләре ут кеби уйнап, зур-зур ачылып, үзенең шул вакытта ни дәрәҗә шат икәнлегене күрсәтеп тора иде. Ул

һәрвакыт һәр сүзене яшь балалар кеби сөенә-сөенә, көлә-көлә сөйли иде. Ул миңа мине йотардай булып күзләрене тутырып карый иде. Кул селкетүләре, йөрүләре, буның кылынышларыннан бер шатлыкка хәзерләнгәннәре билгеле иде. Аның һәр әгъзасы миңа шулкадәр матур, шулкадәр күркәм күренә иде, аның төсле хатын тагы бар дип никадәр исбат кылсалар да, мине ышандыру ихтималлары юк иде. Аның сүз арасында: «Без шулай итәрмез, без болай итәрмез»,— дип, мине кушып әйткән сүзләре, мина тагы аның берлән якынлаштыра иде. Минут саен безнең арамызда пәрдә бетә иде, минут саен бер-беремезгә якынлаша бара идек, минут саен үземезнең мәсгудлекемезгә ышана идек. Икемез дә шат идек, ачык идек, мәсгуд идек.

Ул үзенең ире янына барырга бер дә теләмәсә дә, әллә нинди күңеленең бер кырые сизенгән кеби, шул юлга чыгуны күңеле тартуыны һәм мине күргәч танышырга теләвене, танышкач та арамызда шундый эшләр булуыны, минем шундый кеше булып чыгуымны, әллә нинди бер мәгънәви сергә юрый иде.

Иптәш марҗасы: «Аш ашыймызмы?» — дип сорагач, мин: «Вакытмыни?» — дидем. Ул да: «Сәгать дүрт», — диде. Без Гөлгыйзар белән биш сәгатьнең шулай тоелмаенча үтүенә гаҗәпкә калдык. Гөлгыйзар миңа карап: «Сез дә монда ашаңыз!» — диде. Мин: «Ярар», — дидем.

Марҗа аш картасыны алып әүвәл миңа бирде. Мин нәрсәгә икәнене белмәенчә кулымда әйләндерә башладым. Марҗа көлде дә Гөлгыйзарга бирде. Ул да алдына куйды да, һаман минем белән сөйләвене өзмәде. Ахырдан марҗа тагы көлде дә: «Нинди ашны билгеләдеңез?»—диде. Без бу нәрсә сорый икән дип гаҗәпкә калдык. Ахырдан ул сөйләп биргәч, без үземез сүз берлә мавыгып, белми калуымызны белеп, һәммәмез бик көлештек тә, марҗага аш кушарга үтендек. Озак үтмәде, аш килде. Без бергә аш та ашадык. Без, теге марҗаның киңәше берлән, теге татарларга әһәмият бирмәенчә, бу көн дә йөриячәк булдык. Шулай итеп, парахут өстенә дә чыктык, теге татарларны күрмәгәнгә салынып, тагы көлешә-сөйләшә башладык. Мин Гөлгыйзарга карап:

— Гөлгыйзар! Беләмсең, безнең бу эшемезне бөтен Казан сөйләр бит! Буннан кечкенә эшне дә хәзрәтләреннән алып кер юучы хатыннарына кадәр

авыздан авызга өзми сөйли торган халык моны бөтен мәҗлесләрдә, җәмгыятьләрдә сөйләрләр, сиңа бик авыр булмасмы соң? —д идем. Гөлгыйзар миңа карады да:

— Син өч балаклы ыштан кыйссасыны ишеткәнең юкмыни? Без дә өч балаклы ыштан тегәрмез,—диде. Мин:

— Ничек ул?—дидем. Ул сөйләргә башлады:

— Бер байның кызы үзләренең хезмәтчеләренә чыккан, ул үзе Казанда инде. Шуннан бөтен Казан халкының ире-хатыны моның тугрысында сөйли башлаган. Моның бер асрау хатыны бар икән. Ул кайдан ишетеп кайтса да: «Бикә, сине шулай сөйлиләр, болан сөйлиләр!» — дип, һәммә хәбәрне китерә генә тора икән. Беркөнне теге кыз өч балаклы ыштан теккән дә, бу абыстайны талчукка сатарга чыгарган, талчукның бөтен халкы ябырылып алып, бөтен базарны күтәргәннәр. Моннан сон һәммәсенең авызында шул ыштан булган. Теге абыстай кайткач, бикәсе: «Ни булды?» — дип сорагач, абыстай бермә-бер ни булганыны сөйләп биргән. Иртәгесен тагы теге ыштанны абыстай чыгарган булса да, теге абыстайның янына килүче дә булмаган, күргән бер кеше карамый да китә икән. Ул көнне кайткач, бикәсе сораганда, теге абыстай: «Бер кеше дә сорамады», — дигәч, бикә: «Менә безне дә шулай кызу вакытында сөйләрләр-сөйләрләр лә арыгач туктарлар, без рәхәтләнеп гомер итәрмез», — дигән. Шуның кеби безне дә сөйләрләр-сөйләрләр дә арыгач туктарлар, без рәхәтләнеп гомер итәрмез, — диде.

Анын кыйссасына мин гаҗәпкә калдым. Бик кыска булса ла, бик мәгънәле иле.

Аннан мин яңадан карендәшләрене-фәләннәрене сораштым. Ул әйткән бере миңа әллә кайчаннан бирле үземә карендәш кеби күренәләр иде. Иртә берлән Гөлгыйзар чыкмагач, аңар язып, маэленнән шикләнеп бирми калдырган хатымны күрсәттем. Ул уйлап кына укыды да миңа карап көлде. Хат шулай язылган иде:

«Гөлгыйзар!

Синең авыруыңны белеп кәефсезләндем, хәзер бик эчем поша.

Нишләргә дә белмим. Син ничек авырыйсың? Әллә кәефең юкмы? Әллә миңа ачуландыңмы? Гөлгыйзар! Булган эш булган, миңа үпкәләмә, күңелемдә сиңа зарар итү юк. Гөлгыйзар! Синең берлән сөйләшмәенчә минем күңелем басылмый. Гөлгыйзар, мине дә кызган! Валлаһи бер эш тә эшли алмыйм. Укырга тотындым, укый алмыйм, кеше берлән сөйләшәсем килми. Гел синең тугрыңда гына уйлыйм. Гөлгыйзар! Гомер ике килми! Мондый вакытларда, һич булмаса, сөйләшеп торуыңны гына кызганмасана! Миңа бик-бик оят инде, болай язу да... Нишлим, Гөлгыйзар! Язмыш шулайдыр.

Гөлгыйзар, Гөлгыйзар! Ай, Гөлгыйзар! Син белсәң иде, шул Гөлгыйзар дигән сүзнең миңа ничек тәэсир кылганыны?!

Гөлгыйзар, син ник миңа очрадың? Гөлгыйзар, син ник минем берлән сөйләштең? Гаепләмә димим, гаеплә! Гаеплә! Мин сине, Гөлгыйзар, гомеремә онытмам. Гөлгыйзар, Гөлгыйзар! Миңа бүген ник карамыйсың да? Үпкәләдеңме? Ай, Гөлгыйзар, Гөлгыйзар!!»

Бу хатны мин теге татарларның сөйләүләрене белүдән элек язган идем, теге маржа әйткәч, хатны язып бетерә алмаган идем, һәм бирмәгән дә идем. Гөлгыйзар:

— Хәзер син теләгәнчә булды! — диде. Мин шулкадәр шат идем, һич әйтеп бетерерлек түгел. Гомеремдә андый шат булганым һич юктыр, булса да моннан ун ел яисә сигез ел элек, корбан гаете көнне өстемә яңа киемнәр, башыма яңа кәләпүш киеп, казаки кесәсенә чикләвек тутырып: «Әләлеки кызыкый, әләлеки кызыкый! Нәрсәм бар?!» —дип, малайлар кызыктырган көнне генә шулкадәр шат булсам булганмын.

«Мин кияү булгач — төн кыскарды» сүзе безгә дә килде. Әллә ни арада төн булды. Гөлгыйзар минем берлән күрешеп түбән төшеп китте. Ул миңа шул вакыт беренче мәртәбә уларак күрешергә кулыны сузды. Мин кулыны кысып, иртәгә иртүк «...» шәһәренә йетәчәк булганга, үзем торгач та уятачагымны вәгъдә итеп, Гөлгыйзардан аерылдым. Гомеремдә беренче мәртәбә кызлар кулы тотуым булмаса да, кызлар кулының беренче мәртәбә шулкадәр хисләр уяндыруы иде. Озак кына күрешкәннән сон, бер- беремезгә карашып: «Кичләр

сәламәтлектә үтсен!»—дип аерылыштык.

Мин парахут өстендә ялгыз калдым. Эчемә тулган уйларга, фаразларга чыдаша алмаенча, парахутның бер башыннан бер башына йөри идем. Бүгенге көнне башыннан ахырына кадәр уйладым. Үземнең башымнан үткән эшләргә үзем ышанмый идем. Миңа бу эшләр һәммәсе төшемдә кеби күренә иде. Фәкать Гөлгыйзарны гына төшемдә күргән кеби иттереп уйлый алмый идем. Чөнки аның үткен, җазибәле күзләре, алсу-кызыл йөзләре, тезеннән үткән сачләре, кечкенә генә сары башмак кигән аяклары күз алдымда: «Син теләгәнчә булды!» — дип торган кеби була иде. Шулай итеп, уй артыннан уй китте. Бара-бара баягы Зәбирнең хаты да килеп чыкты. Күз алдымда яшь кенә бер егет, күңелсез генә: «Мине саргайтма, кил! Ат алдым, арба алмакчы булып торам, кырларга чыгармыз, бик кызык булыр!» — дип әйткән кеби күренә башлады. Аның артыннан Гөлгыйзарның этиләре-әниләре күз алдыма килә башладылар. Аның артыннан өч балаклы ыштан, базар тулы талчук халкы, әллә нинди караңгы гына голямалар мәҗлесе, ахырдан гына күз яшьләре берлән үз анам күз алдымда күренә башлады. Бу уйларны никадәр бетерергә теләсәм дә, һаман бетми иде, киткәннән китә бара иде. Әллә нинди ямьсез күренешләр, Голгыйзарнын авырулары, ире берлән әллә нинди фаҗигале күренешләре килә башлагач, уемны Казандагы иптәшләремә бормакчы булдым. Һәммәсе дә Гөлгыйзар тугрысында сөйлиләр, һәммәсе дә миңа: «Бу нишли?!» — дип караган кеби күренәләр иде. Үзем дә уянып киткән кеби булдым: «Ник мин болай кылынам? Бу кеше хатыны бит. Моннан бер эш чыкмас!» — дип, Казанда күңелемнән яратып йөри торган кызымны, үземезнең яктагы алырга ярый дип йөргән кызны уйламакчы булдым. Кайсысыны гына уйлап карасам да, Гөлгыйзар булып чыга иде. Ахырдан, анларның һәммәсенең дә Гөлгыйзар берлән югалуларыны белдем.

Мин, иртәгә иртүк торасы булганга, тизрәк төшеп яттым. Күз алдыма тагы әллә ниләр күренә башлады. Бер ягымда Гөлгыйзар йөзене чытып: «Ник юк сүз әйтәсең, күз алдымда булса, менә хәзер атар идем!» — дигән сүзне әйткән кеби күренә иде. Икенче ягымда, башыны иеп кенә, Зәбир: «Мине

саргайтма, кил! Ат алдым, арба алырга торам, кырларга чыгып йөрермез, бик кызык булыр!» — дигән кеби күренә иде. Гөлгыйзарны уйлап китеп: «Нинди зур эш кылдым, гөнаһсыз бер баланы сәгадәткә ирештерәм, нинди фидакарьлек кылдым. Бундый эшне күңеле били торган кешеләр генә кыла ала, нинди гали эш!» — дип вөҗданым рәхәтләнә иде. Шуның өстенә, Гөлгыйзар үзенең зифа буе берлән, иске замандагы хан сарайларындагы кызлар кыяфәте төсле кыяфәтләре берлән минем алдымда: «Инде син теләгәнчә булды!» — дип торулары минем фидакарьлегемнең мәгънәсез түгеллекене дә күңелемә төшереп, мине шатландырганнан шатландыра иде. Шуның артыннан, безнең авылда Гөлгыйзар берлән бергә торуларымыз, кичкә кырын сандугачлар сайраганда ай яктысында тып-тын гына тора торган бакчада кулга-кул тотынышып, акыртын гына, сөйләр-сөйләмәс кенә, үземезнең мәсгудлекләремезне белеп, эчемездән бер- беремезгә рәхмәтләр укышып йөрүләремезне, акыртын гына кул кысышуларымыз, безнең сөешүләремезнең дөрестлегене белдерә торган шаһидләр кеби, ерактан гына кычкырган әтәч тавышларыны, күлдәге бака тавышларыны, аның артыннан яфраклар арасыннан гына күренә торган ай шәүләсендә бер сүз ишетмәенчә, кинәттән генә сарылып, озак-озак кысышып-кысышып үбешүләремезне күргән кеби була идем. Аның артыннан безнең дә арбамыз, атымыз берлән кырларга чыгуымыз, балалар төсле уйный-уйный чәчәкләр җыюымыз, тагы кулга-кул тотышып ерак елга буйлап артка карамаемча китүләремез, кырда бер-беремезгә күзләремезне тутырып карашуларымыз булган кеби күренәләр иде. Аның артыннан, арбалары, атлары берлән Зәбир күренә иде. Ул еглый иде, алына иде, ялвара иде: «Гөлгыйзар, саргайтма!» — дип, Гөлгыйзарны үз янына утырырга чакыра иде, Гөлгыйзарны тота башлый иде. Безнең баягы сәгадәтләр, баягы ай яктысындагы кичләр югала иде, баягы фидакарьлекләр, баягы Гөлгыйзарлар тотыла торган ай кеби караңгыланганнан караңгылана бара иде.

Менә кап-караңгы... Гөлгыйзар да юк, бакча да, рәхәт тә юк, сандугачлар да сайрамый, бакалар да кычкырмый. Караңгыланганнан караңгылана бара...

Ерактан гына эт чавышлары ишетелә... Гөлгыйзар да әллә кая, караңгы артында кеби генә күренә башлады!..

Мин, бу ямьсез уйларны баштан йебәрер өчен, бик тиз икенче якка әйләнә идем. Күңелемә кылт итеп тагы Зәбир килеп чәшә иде. Ул миңа карап: «Син Гөлгыйзарны мәсгуд ясамакчы буламсың? Мин мәсгуд булырга ярамыйммыни ? Мин кеше түгелмени?! Минем ник бар сәгадәтемне аласыз? Мин Гөлгыйзарсыз тора алмыйм!!» — дигән кеби була иде. Мин, авызыма бармагымны кабып, Гөлгыйзар берлән Зәбир арасында ни әйтергә белмәгән кеби торган төсле була идем. Беремез дә дәшми идек, һәммәмез уйга чумган идек, һәммәмез мәсгуд булырга тели идек, һәммәмезгә дә сәгадәт юлы капланган иде! Бу күренеш моң иде, еглыйсыны кичерә иде, кызганыч иде, аяныч иде, бәхетсез иде!..

Мин тагы икенче якка әйләндем. Миңа, вакыйган, Гөлгыйзарны мәсгуд итәм дип, Зәбирнең сәгадәтене тартып алырга минем хакым бармы-юкмы мәсьәләсе килеп төште. Мин бу эштә яхшылык кылдыммы, начарлык кылдыммы мәсьәләсе башымны вата башлады. Мин никадәр мәшәкатьләнсәм дә, буңар җавап бирә алмый идем. Ахырдан гына Гөлгыйзарның: «Язмыш шулайдыр!» — дигән сүзе берлән үземне юата башладым. Аның артыннан: «Кешене кызганма, кызганыч булырсың!» — дигән сүзе колагыма ишетелә башлады. Мин ничек тә җавап бирә алмагач, ни булса да булыр, дип, язмышка тапшырып, йокларга хәзерләндем. Тагы әллә нинди уйлар берлән бик озак чуалганнан соң йокыга киттем.

Иртәгесен торып, әйберләремне җыештырып, юынып, киенеп, парахут өстенә чыктым. Ерактан гына «...» шәһәре күренә башлаган иде. Көн бик матур, кояш күптән түгел генә чыкканга, бик эссерәп йетмәгән иде. Парахутның ул ягыннан да, бу ягыннан да өзелмәенчә саламнар агалар иде. Идел кырыенда башкортлар «әҗәл тагарагы» кеби көймәләр берлән балык сөзәләр иде. Идел буендагы ашлыклар өстендә тургайлар ояларыннан кузгалып бормалана-бормалана очып сайрыйлар иде.

Ул арада «...» шәһәре якынайганнан якыная бара иде. Күренешләре дә

таулар, урманнар, тимер юллар, мәсҗед манаралары берлән матурайганнан матурая бара иде. Тегеләрне уятырга вакыт йетүене белеп, ишекләрене как-тым. Озак үтмәде, ай кеби ялтырап, минем каршыма Гөлгыйзар килеп чыкты. Мин сәламләшкәннән соң, «...» шәһәренә йетүемезне, хәзерләнергә вакыт икәнлегене әйттем. Ул:

— Хәзер марҗалар бераз торып бетсен дә минем әйберләремне җыештырышырсың, — диде. Мин, парахут өстеннән тагы бер әйләнгәннән соң, аның янына кереп әйберләрене җыештырдык. Мин, теге көнге сүзем буенча, аны озатырга барачак идем. Парахут кычкырткач, без эшләремезне бетереп, парахут өстенә чыктык. Озак үтмәде, без «...» шәһәренә барып йеттек. Теге марҗаларның күбесе берлән күрешкәннән соң, мин үземнең әйберләремне парахут кантурында сакларга калдырып, Гөлгыйзарның әй-берләре берлән вокзалга киттек.

Без вокзалга барганда сәгать сигезләр иде. Безнең бәхетсезлегемезгә каршымы, бәхетлелегемезгә каршымы, әллә иттифакый гынамы, поезд өйләдән соң сәгать икесез булмаячак иде. Без төрлечә уйлашканнан соң, «...» шәһәренә менеп бераз йөрергә, бер-бер йергә кереп ашарга-эчәргә исәп итеп, аның әйберләрене шундагы кешеләргә карарга кушып, извозчик яларга тотындык. Извозчик яллап утырган гына идек, вокзалдан әллә нинди ике татар егете килеп чыкты. Гөлгыйзар күргәч тә:

— Минем каен энемдер ахырысы!—диде. Мин, ни булса, ул булыр дип, извозчикка тизрәк барырга куштым. Теге егетләр безнең арттан йөгерделәр дә, әллә кая калдылар... Без аларны күздән югалттык. Без Гөлгыйзар берлән, ни булса да, үземезчә эшләмәкче, алар артымыздан килсәләр дә, әһәмият бирмәенчә, гостиницага керәчәк идек. «...» шәһәренә менеп йеттек. Безнең арттан килгән кеше юк иде. Без, гостиницада аулак булмас, теге татарлар килер-фәлән дип, номер алдык. Киемнәремезне салып, чәй китертеп, эчәргә утырдык.

Гөлгыйзар иртәге Гөлгыйзар түгел иде. Аның ялтыраган күзләре, караган саен карасы китерә торган йөзләре әллә нинди бер моңлык берлән

капланган иде. Ул миңа үзенең кәефе китүене белгертәсе килмәсә дә, мин аны үтәли күргән кеби, ни уйлаганнарына кадәр беләидем. Ул, теге татарларның килүләреннән, әллә нинди бер-бер тавыш чыгуыннан, безнең бәлки актыккы утырышларымыз, актык мәҗлесләремезнең бер зур кәефсезлеккә сәбәп булуыннан курка иде. Мин аны юатып:

— Гөлгыйзар, кәефсезләнмә, берни дә булмый! Татарлар килә икән, мин үзем җавап бирәм, кайгырма! Элгәреге Гөлгыйзар бул әле! Бундый йердә без тагы кайчан күрешермез, — дидем. Гөлгыйзар көлде дә:

— Юк, мин аны уйламыйм, башым гына бераз авырта, — диде. Ләкин аның бу көлүе, парахутта аш ашагандагы, берәмләп-берәмләп тәрилкәдән җиләк ашагандагы көлү түгел иде, бу үзене миңа кәефле күрсәтер өчен, минем кәефемне китерер өчен уйлап кылган үзене икенче төрлеләндерү генә иде. Ләкин озак үтмәде, болытлы көн ачылган кеби, Гөлгыйзар да ачылды. Без тагы «киләчәк» планнарны кора башладык. Озын иттереп чәй эчтек; күп сөйләштек, күп көлештек. Тимер юлда тагы рәхәтләнеп бергә баруларымызны искә төшереп, тагы шатланыштык.

Без кергән бүлмәнең тәрәзәсе йорт ягына караган иде. Бүлмә чиста гына, пакь кенә иттереп җыештырылган иде. Уртасында зур көзге ялтырап тора иде. Көзге тугрысында йомшак кәнәфи, аның каршысында өстәл, яннарында мен-дәрле урындыклар тезелгән иде. Гөлгыйзар, кәнәфигә утырып, чәй ясый иде. Мин дә аңар ян берлән урындыкка утырган идем. Нумирда, йортта, хәтта бөтен шәһәрдә тып-тын кеби иде. Бер йердә дә тавыш юк иде. Акыртын гына искән җил берлән тәрәзәнең челтәр пәрдәсе иренеп-иренеп кенә селкенгән кеби була иде. Менә озак үтмәде, акыртын гына, шыпыр-шыпыр гына ягмур ява башлады. Без Гөлгыйзар берлән тәрәзә төбенә барып карый башладык. Тәрәзә ачык иде, пәрдәсе төшкән булса да, һәммә йорт ап-ачык күренә иде. Мин тәрәзә тугрысына барып бастым. Гөлгыйзар, миңем сул яныма килеп, кулы берлән җилкәмә таянды. Бер-беремезгә бер сүз әйтмәенчә, шәһәрнең күренешене тамаша кыла башладык. Күрше йорттагы биек каен, җил берлән иелеп-иелеп, акыртын гына шаулый иде. Бунынң иелүләре безгә гаҗәпкә

калганга шулай кылынган кеби дә була иде, безгә: «Мөбарәк булсын!» — дип, тәбрик иткән төсле дә булган кеби дә күренә иде; «Әй, сез, нишлисез?» — дип, ачуланып, бармак селеккән кеби дә тоела иде. Мин, күземне алмаенча, шунда карый идем. Гөлгыйзар, яннан гына миңа күзләрене тутырып-тутырып кына карап, минем уйлаганнарымны җентекләп тора иде. Мин аның карауларыны һәммәсене сизә идем. Мин уйга чумганнан чума идем. Аның ул карашы сине исерткән кеби була иде, йоклаткан кеби була иде, минем тамырларыма әллә ни йебәргән кеби, эчемнән шатландыра иде. Безнең бу хәлемез дә, әллә кайдан килеп чыгып, безнең тугрыга гына килеп уйный башлаган орган тавышы берлән бозылды. Мин бик тиз генә Гөлгыйзарга борылып карадым. Безнең күзләремез бер-беремезнеке берлән очрашты. Ул көлебрәк кенә:

— Ни уйладың? — диде. Мин:

— Сине, мине, безне, — дидем. Органчы һаман уйный иде. Ул безнең икемезнең тамырларымыздан йөри иде. Икемезгә бер төрле хиссият уяндыра, икемезгә дә, тормышка мәхәббәт арттыра иде. Икемезгә дә бергә-бергә торуда гына рәхәт барлыгыны исбат кыла иде.

Безнең икемезнең күңелемез бер-беремезгә мәхәббәт, сөю берлән тулган иде. Без берне уйлый идек, берне тели идек. Без берәм-берәм юк идек, без — бер идек!! Гөлгыйзар минем сул кулымны кыса башлады. Аның ул кысулары миңа: «Әйе бит, дөрест бит, без — бер бит!» — дигән кеби була иде. Аның ул кысулары, электрик кеби минем бөтен тәнемә тәэсир кылды. Мин дә, ул да якынайганнан якынлаша идек. Якынлаша-якынлаша, мин кинәттән кысып кочакладым. Ул минем кочагыма атылды. Бик озак, бер-беремезне белмәенчә торганнан соң, күзгә-күз караштык та, үбешергә тотындык. Бу минутлар шулкадәр татлы, шулкадәр рәхәт иде — әгәр ул минутлардан соң рәхәттән зур хәсрәт, кайгы калмаса иде, адәм баласы шуның өчен генә дөньяда торса да, гомерендә шундый минутларны бер генә күрсә дә, «гомерем бушка үтте!» дияргә ярамас иде. Ай, шул ахыры булмаса иде! Ай, шул сәгадәтләрне искә төшерү синең бөтен гомереңдәге кайгыларны искә төшерергә сәбәп кенә булмаса иде!

Органчы көйне үзгәртте. Моң иттереп, русларның «Разлука» («Аерылышу») көене уйный башлады. Без дә, ни эшләгәнемезне белмәенчә, бер-беремездән аерылыштык. Ул барып караватка утырды.

— Нишләдем мин! Мин бит кеше кешесе?! — диде. Тагы бераздан, күзләрене зурайтып, әллә нинди тавыш берлән:

— Түгел! Аның хатыны түгел!! Теләсәләр нишләсеннәр, түгел, түгел!..—диде. Башыны бөгеп, күзләрене түбән төшерде. Мин аңар ни әйтергә дә, кайсы яктан сүз башларга да белми калдым.

Орган һаман уйный да уйный иде. Мин дә, ул да бу көйнең безнең көемез икәнлегене бу рус малае, белгән кеби, безгә шуны уйнавыны, безгә кайчан да бер аерылырга тиеш булуыны, бәлки бөтенләй гомер буе күрешә алмауларымызны сиздерә башлаганга, ул да миңа башыны күтәреп карады. Мин ни әйтергә дә белмәдем. Күңелемнән генә: «Ни булса, ул булыр», — дия идем. Ул эченнән генә: «Язмыш шулай булгач!» — дигән кеби, өметсез-өметсез карашлар берлән миңа карый иде. Ул миңа бераздан соң:

— Габдулла!—диде. (Ул шул вакытка кадәр исемем берлән әйтмәгән иде.) Мин:

— Нәрсә? — дидем. Ул:

— Без нишләдек? Бу эштән ни чыгар?—диде. Мин:

— Ни чыкса, шул чыгар, син әйткәнчә, язмыш шулайдыр, хәзер кайгыруда файда юк, — дидем. Ул да:

— Әйе, ни булса, ул булыр! — диде дә, торып, үз урынына килеп утырды. Мин дә, бүлмәдә бер-ике әйләндем дә, янына килеп утырып, сүзне икенчегә бордым.

Органчы тавышы бетте. Болыт астыннан ялт итеп кояш килеп чыкты. Тыштан кергән ягмур исе берлән безнең бөтен бүлмәмез тулды. Без, тагы, берни дә булмаган кеби, бер-беремезгә карашып, сөенешә-сөенешә сөйләшеп, чәй эчә башладык. Чәй арасында Гөлгыйзар үзенең әллә нинди бер карендәш хатыныны күрергә кирәклегене, анларны теге парахуттагы татар хатыннарының белүене, анлар әйткәч, бәлки анда хәзер Гөлгыйзарны

көтүләрене сөйләп, тизрәк төшәргә хәзерләнә башлады. Мин дә разый булдым һәм без вокзалга төшеп киттек. Вокзалда безне бер кеше дә көтми иде. Поезд китәргә бер-ике сәгать бар иде. Гөлгыйзар:

— Теге кешеләр, күрәсең, анлар булмадылар, анлар булса, бунда булырлар иде, — дип, бераз күңеле басылды. Теге абыстайга үзенең менәсе килми иде, әмма күрәсе килә иде. Шуның өчен, кечкенә генә записка язып, бер извозчик артыннан йебәрдек. Гөлгыйзар, тәрәзәгә кулы берлән таянып, анларны көтә башлады. Мин аның янында тора идем. Озак үтмәде, Гөлгыйзар миңа карап:

— Баягы егетләр әнә киләләр, син шунда тор әле, айларга күренмә, мин хәзер керәм, — диде дә анларга каршы чыгып китте. Бераздан соң мин иптәш русыма чыгып карарга куштым. Ул кергәч:

— Гөлгыйзар кызып-кызып кына сөйли, егетләрнең берсе читтә, берсе Гөлгыйзарның сүзене тыңлый, — диде. Бераздан соң тагы чыгып карады, тагы шул җавап берлән керде. Тагы никадәрдән соң өченче чыгаруымда:

— Ул анда юк, теге егетләр дә юк ,— дип керде. Мин анлар торган йергә чыгып карасам да, урыныннан җилләр исә иде. Шундагы кешеләрдән сорадым:

— Аны алып киттеләр, — диделәр...

Гөлгыйзар югалды!.. Кая китте? Гөлгыйзар ник китте?! Ул татарлар белән ни сөйләштеләр?.. Әллә ул ире идеме?! Инде ничек күрермен? — сөальләренә һич җавап бирә алмый идем. Ауга төшкән балык кеби, ары бәрелдем, бире бәрелдем — һичбер эш чыгара алмадым. Ахырында поезд киткәнче көтәчәк булдым. Аны да көттем, Гөлгыйзар поездга да килмәде. Мин, ни эшләргә белмәенчә, әйберләремне алып, нумирга менеп киттем. Ул хат язган өйнең адресын белгәнгә, шул хат берлән бу егетләр төшкәнгә, мин үз исәбем берлән теге марҗаны табып, ялынып, Гөлгыйзарны белешергә йебәрәчәк булдым. Шуның өчен «,..» шәһәренә кергәч тә, шәһәрнең бөтен нумирыннан аны эзләп арып беттем, йөдәдем, таба алмадым. Ул йортка үзем

барырга һич хәйлә таба алмадым. Икенче бер кеше йебәрергә — андый кеше юк иде; икенчедән, хәйләсе юк иде. Мин, теләр-теләмәс, бу эшне иртәгегә калдырдым. Өч-дүрт көн рәтләп йоклый алмавымнан, бу көн көн буе эт кеби йөрүемнән, руханда шул көндә генә булса да бер гомер торуымнан мин җисмән һәм рухан һәм бик арыганга, сораучы булса, уятырга кушып, йокларга яттым.

Күз алдыма тагы Гөлгыйзар килеп төште. Ул авырый төсле дә күренә иде. Аны тиргиләр, кыйныйлар, әллә нинди сүзләр берлән йөдәтәләр дә төсле күренә иде. Шулкадәр арыган идем — һичбер нәрсәне башыннан алып ахырына кадәр уйлап чыга алмый идем. Яисә башында, яисә уртасында икенче бер уй берлән чуала идем дә, тагы ахырдан әллә нинди Гөлгыйзарның: «Коткарыңыз, коткарыңыз!» — дип кычкырулары берлән, яисә карап, көлебрәк кенә: «Барысы да бетте, барысы да бетте! Уйламаганча чыкты, ирем монда икән, һәммәсене әйттем, син теләгәнчә булды!» — дигән сүзләр берлән бетә иде. Ни уйламакчы булсам да Гөлгыйзар килеп төшә иде дә фикеремне тагы башкага бора иде. Миңа башка кешеләр дә гел шулай Гөлгыйзар тугрысында гына уйлыйлар төсле күренә иде. Фәкать урамдагы извозчикларның, сатучы малайларның шундый кәефсез чакта көлешүләрене аңлый алмый идем. Вакыйган, шундый кайгылы вакытта ни дип көлешергә кирәк?!.

Шулай уйлый-уйлый йокыга китә идем. Тагы төшемдәме, көнемдәме, Гөлгыйзар, теге егетләр, өч балаклы ыштаннар, «Разлука»ны уйный торган органчы, теге марҗа, тагы Гөлгыйзар, Зәбир күз алдымда күренгән кеби булалар иде. Тагы күземне ача идем, тагы уйларым, диңгез дулкыны кеби, берсенә-берсе кушылып, икесеннән бер булып, өченчесе берлән югалып, ерактан еракка китә генә баралар иде. Еракланган саен, ни уйлаганымны, дөресте генә, ни уйланганымны белмәенчә, уем артыннан бара идем. Миңа кәефсез иде, күңелсез иде, әллә нием юк кеби иде!..

Мин тагы акыртын гына йоклап китә идем, тагы Гөлгыйзар берлән бергә була идек. Мин үземнең хәзеррәк кенә, югалды, дип, кайгыруымның юк өчен икәнлегене белгән төсле була идем. Аңар, ул киткәч, нинди уңайсыз булуны

сөйли идем. Ул, күзене зур иттереп ача иде дә: «Инде син теләгәнчә булды!» — дия иде. Мин шатлыгымнан: «Гөлгыйзар!» — дип, муенына асылмакчы була идем, үз тавышыма үзем уяна идем дә, Гөлгыйзарның юклыгыны белеп, тагы кайгыра идем — еглыйсым килә иде. Балалар кеби, Гөлгыйзарга үпкәләсем килә иде, аның аягына егылып, икенче мине алай калдырмасын телисем килә иде. Тагы уйларым чуала иде, тагы Гөлгыйзарга әллә ниләр катыша башлый иде, тагы йоклый идем, тагы уяна идем. Бу кичне үткәрү миңа бик авыр булды, бәла булды, газап булды!.. Йокысызлык, кәефсезлек, эч пошуы берлән җәзаланып, изелеп беткән идем, бер минутта мин йоклый идем, төш күрә идем, уяна идем, төш юрый идем, тагы йоклый идем. Шул җәфалар берлән мин икенче көнгә чыктым. Иртә берлән уянгач та, тиз генә чәй эчеп, тагы теге марҗаны эзләргә тотындым. Йокысызлыктан, күп уйлаудан башым бөтенләй үземнеке түгел иде. Бер эшне башласам, бетерергә уем йетми иде...

«Ничек күрим?.. Исәнме?.. Теге татарлар кыйнамадылармы?.. Мине эзләп тапмаенча, ни эшләргә белми йөрмиме?» — сөальләре һаман сөаль көенчә генә торалар иде. Ахырдан, ат яллап, вокзалга киттем. Минем уем буенча, Гөлгыйзар бу көн китәргә тиеш, әгәр китмәсә, авыруы була иде.

Вокзалга төштем. Анда бардым, бунда бардым: берни юк. Поезд китәр вакыт йетте. Һаман юк иде. Поезд китте. Һаман юк! Минем өметем бөтенләй өзелде! Ни булса да булды, яхшы эш булмады. Гөлгыйзар йә бик каты авырый, йә бик зур эш булды дип уйлый-уйлый йөреп, тагы эт кеби арып, кайтып киттем. Юлда теге марҗа очрады. Вакыйганы баштанаяк сөйләдем. Ул кичә күрешә алмавыбызга бик кайгырды, ләкин вакыт үткән иде: «Хәзер, әйдә, анларга бар!» — дияргә, белмим, мин базмадым, белмим, оныттым. Шулай итеп, аннан да калдым.

Тагы кичкә чикле һәммә йерне аны очрату уе берлән йөрдем. Ләкин беркайда да очрамады. Нумирымнан чыгып киткәндә, өстәл өстемә кәгазь-кара куеп, хезмәтчеләргә:

— Әйтегез, кем булса да, кем икәнене, тагы кайчан киләсене язсын! — дип, кушып чыгып китә идем. Ләкин килүче дә юк иде, очраучы да юк иде.

Мин һаман көндезене Гөлгыйзар артыннан йөреп, кичене аның берлән саташып, өч көнне үткәрдем. Бу көннәрне үткәрү миңа шулкадәр авыр булды, минем ул вакытка кадәр күргән авырлыкларым, өчәр тәүлек ач торуларым, бер тиен акчасыз, бер танышсыз чит шәһәрләрдә йөрүләрем — һәммәсе дә буңар караганда күп җиңел төсле күренәләр иде. Адәм башыннанниләр үтми?.. Ни килсә, шул үтә!.. Минем башымнан да бу көннәр үттеләр. Алай булса да, бу көннәр миңа билгеле булып калдылар. Хәзер уйлап карасам да, һәммәсе күз алдымда төсле күренәләр.

Дүртенче көн, тагы иртүк торып, вокзалга төшәргә ат чакырдым. Утырырга башлагач, извозчик миңа карады да:

— Нигә вокзалга төшәсең, мин нигә төшүеңне беләм бит, ул кыз шул көннүк кичке поездда китте, — диде. Поездны озатачак, һәркөнне өметсез булып кайтачак идем. Мин үземнең кичке поездны белмәвемә гаҗәпкә калдым.

Мин, өметсез көенчә авылыма кайтып, әүвәле телеграмм, аннан соң хат көтә башладым. Һәркөнне, ыстансага барып, телеграмм берлән хат тикшертә идем. Һәркөнне булмый иде, һәркөнне бу нинди эш икәнлегене аңлый алмый идем. Һәркөнне Гөлгыйзарның бу эшенә гаҗәпкә кала идем.

Мин, көтә-көтә, көт булгач, Гөлгыйзар адресы берлән хат яздым. Тагы, фәлән көнне фәлән йердә була, фәләндә була, шул көнне ала, бу көнне җавап яза дип көтәргә тотындым.

Исәпләнгән көнем үтеп тә китте. Гөлгыйзардан һаман хат юк иде. Мин җәй буе шул хатны көттем, җәй буе Гөлгыйзарны уйладым, һаман искечә — аның тугрысында бернәрсә дә белмәенчә, аннан бер хат та алмаенча үткәрдем.

Гөлгыйзар исәнме?.. Аңар ни булды?.. Ник хат язмады, ник җавап язмады? Һичберсен белмәдем. Аның адресы берлән аны эзләп табарга миңа мөмкин түгел иде. Чөнки өй эшләребездән, әниләр, сеңелләремнән аерылырга, тагы шуннан бер кешенең хатынын күрер өчен өйдән китәргә һич мөмкин түгел иде.

Мин үземнән үзем генә кичләрдә, ай яктыларында, бакалар

кычкырганда, этәч тавышыны ишеткәндә, Гөлгыйзарны уйлый идем. Ул күңелемә килә дә төшә иде. Ул һаман әүвәлгечә минем алдыма килеп, күзләрене зур ачып: «Син теләгәнчә булды!» — дигән төсле була иде. Ләкин бу әйтүе теге вакыттагы төсле түгел, бөтенләй башка иде — миннән көлгән кеби була иде...

Мин үзем алган арбага үзем алган кара атымны җиккәч тә, Гөлгыйзар минем яныма чыгып утырыр төсле була иде. Ул һаман булмый иде. Мин аңар: «Мине саргайтма, кил! Ат алдым, арба алдым, кырларга чыгам!» — диясем килә иде.

Кайвакытта ат, җиккәч, бик моң иттереп кешнәп йебәрә иде дә, миңа ул Гөлгыйзарны юксынганнан шулай кешни кеби була иде. Үзем дә, тагы Гөлгыйзарның юклыгыны сизеп, күземнән яшьләрем чәчрәп чыгып китә иде. Мин, кырга ялгыз чыгып, һәрнәрсәдә моңлык, һәрнәрсәдә кәефсезлек күреп керә идем. Һәрнәрсә миңа Гөлгыйзарның юклыгыны белгертә, һәрнәрсә миңа, моңаеп кына, кызганып кына караган төсле була иде. Мин кайвакытта: «Ничек бу Гөлгыйзар мине кызганмый икән?» — дия идем. Шуның артыннан ук миңа Гөлгыйзарның ире хакында: «Кешене кызганма, кызганыч булырсың!» — дигән сүзе колагыма чыңылдап ишетелә башлый иде дә, бу кагыйдәне минем хакымда да йөретә микәнни дип, исем китә иде. Кайвакытта, Гөлгыйзар күземә күренгән кеби була иде дә, минем: «Гөлгыйзар, ник болай иттең?» — дигән сүземә каршы: «Язмыш шулай булгандыр», — дигән төсле була иде.

Белмим, язмыш шулай булгандырмы, әллә башка бербер сәбәп чыккандырмы, мин Гөлгыйзарга тагы хатлар язсам да, җавап ала алмадым.

Бер-ике ел, бәлки Гөлгыйзардан хәбәр килер, бәлки ул, бәлки бу дип тордым; ләкин аның хакында һичбер мәгълүмат ала алмагач, мин дә аның тугрысында бик уйламый башладым. Аның төсләре, кыланышлары, сүзләре һаман ерактан еракка китә генә бара-бара, куе бер томан берлән капланган кеби югалды...

Гөлгыйзарның җавап бирмәүләрене миңа бер дә әһәмият бирмәвенә, исе китмәвенә багышлый алмый идем, чөнки Гөлгыйзар шулкадәр ялган сүзләр

сөйләрлек кыз түгел иде. Шуның өчен ул һаман мине сөя, ул һаман мин теләгәнчә разый булса да, әллә нинди эшләр аны бәйләп тота төсле күренә иде.

Ул эшкә инде ун ел булды.

Берничә елдан соң мин өйләндем. Хәзер балаларым да бар, хатыным берлән дә яхшы торам. Ләкин Гөлгыйзар һаман юк!!.—дип Габдулла әфәнде хикәясене бетерде.

## III

Без һәммәбез дә тынымызны чыгармаенча тыңлап тордык. Ул бетергәч тә беребез:

— Шуннан соң Гөлгыйзарны күргәненез дә юкмы? — диде.

Габдулла әфәнде:

— Бервакытны мин көзгә табарак кына Казан урамыннан хатыным, угылым берлән кавын алып кайтып килә идек, шул вакытта бер ир кеше, бер хатын әйберләре берлән извозчикта каршы килеп үтеп киттеләр. Шуның хатыны Гөлгыйзар төсле булган иде. Белмим, ул иде, белмим, түгел, тәмам күреп бетерә алмадым, — диде.

Безнең иптәшләремез Габдулла әфәндегә беравыздан рәхмәтләр укып, вакыт йеткәнгә, кайтырга хәзерләнә башладылар. Габдулла әфәнде дә үз рәтендә:

— Юк сүзләр берлән сезне чәй зчерми калдырдым, дип гафу үтенде.

Башкалар китә башлагач, мин Габдулла әфәндене бераз читкәрәк алып киттем дә:

— Мин вак-төяк нәрсәләр язгалыйм һәм язарга бик яратам, әгәр рөхсәт бирсәңез, сезнең бу вакыйгаңызны кулдан килгән кадәр үзгәртмәенчә язар идем, — дидем.

Габдулла әфәнде бераз уйлап торды да:

— Мин разый, ләкин бу минем серем генә түгел, Гөлгыйзар, күргәч,

ни әйтер икән соң? — диде. Тагы бераз уйлаганнан соң:

— Язынгыз, берни әйтмәс! «Язмыш шулайдыр», дияр дә калыр,— диде.

Мин яздым.

*Соң.*

**Искәртмәләр һәм аңлатмалар:**

*Инсанның хакыйкате — хайване натыйк, ишәкнең — хайване сахил* — кешенең асылы — сөйләшә (аңлый) торган хайван, ишәкнеке — кычкыра торган хайван.

*Хамияте исламия* — ислам өчен яну.

*Билфигыль* — чынбарлыкта.

*Җөннүн* — акылсызлык.

*Мүхзүн* — сагышлы.

*Мөбтәля* — кайгырту.

*Кимпер* — карчык.

*Иттифакый* — очраклы.

*Ләтафәт* — гүзәллек, матурлык.

*Аләт* — корал; бу урында: ысул.

*Кальби* — йөрәккә кагылышлы.

*Әүһам* — буш уй.

*Ифрат, тәфрыйт* — чамасызлык, чиктән тыш арттыру яки киметү.

*Вөкугат* — вакыйгалар.

*Мәгънәвияткә инкяр кылалар* — идеаллыгын кире кагалар.

*Сәбәбе маддисыны инкяр кылу* — матди, материаль сәбәбен кире кагу.

*Маддиуннар* — материалистлар.

*Мәгънәвиуннар* — идеалистлар.

*Вакыйгада* — чыннан да.

*Тарыз* —рәвеш.

*Мәсгуд* — бәхетле.

*Мохалиф* — охшамаган.

*Сарфы гарби* — гарәп теле морфологиясе.

*Тәҗвид* — Коръән уку кагыйдәләре.

*Бәян кылу — аңлату.*

*Биөмиданә, бирафиганә* — өметсез, төшенке;

*Мөгаризә* — каршылык.

*Тәгърифф* — анлату,

*Ригая* — кайгырту, игътибарлы булу.

*Ифтира* — яла ягу.

*Нәфселәмер* — асылда.

*Истиляхи* — шартлы.

*Тәгассыб* — фанатизм.

*Вөҗданә мөгаззиб* — вөҗданын газаплаучы.

*Гадесөле* — линзалы, лупалы.

*Бәдбәхет* — бәхетсез.

*Сайа* — санау.

*Кәшеф* — ачу.

*Мәсгуд* — бәхетле.

*Аш картасы* — меню.

*Маэль* — эчтәлек.

*Җазибәле* — кешенең күңелен үзенә тарта торган.

*Голяма* — укыган, белемле кешеләр.

*Вакыйган* — чыннан да, дөрестән дә.

**Очрашу яки Гөлгыйзар**. — Повестьны басарга рөхсәт С.-Петербургта 1902 елның 30 декабрендә бирелә. Оренбургта М.-Ф. Кәримов типографиясендә 1903 елда басылып чыга. 56 бит. Имза: Мөхәммәдгаяз әл-

Исхакый. Соңгы битендә: «Бетте 1902 нче сәнә, 22 нче июль, Госман авылы» днп куелган.

Әсәрнең икенче басмасы Казанда И. Н. Харитонов типографиясендә 1911 елда чыккан. Автор «роман» дип куйган. Г. Исхакыйның «Мәҗмугаи аса ре», 1 нче җилд, 3 нче китап, 106—158 битләр.

Җ. Вәлиди бу әсәр хакында: «Очрашу"сы илә бик зур алга атлый. Монда Гаяз шагыйрь күренә, бу әсәр «Инкыйраз»ларны, «Сөннәтче бабай» ларны вәгъдә итә»—дип яза. *(Гаяз әфәнде.— Вакыт. 1913, 5 март).*

Текст әсәрнең икенче басмасыннан алынды.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 1 том. - Казан:
Татарстан китап нәшрияты, 1998. Б. 79-112.
Текстны әзерләүче: Лена Гайнанова